**Каюм Насыйри** **Каюм Насыри**

*И туган тел, и матур тел...*

www.каюмнасыйри.рф

# Китаб-эт-тәрбия

# Книга о воспитании



ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО

УДК 37.018.1
ББК 74.9
Н26

Книга издана при поддержке Комиссии при Раисе Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан

**Каюм Насыри**

Н26 Китаб-эт-тэрбия = Книга о воспитании. — Казань: Татарское детское издательство, 2024. — 232 с.

ISBN 978-5-6050160-2-1

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән әзерләнгән әлеге китап күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның кыйммәтле мирасын торгызу һәм популярлаштыруга багышлана. Укыту һәм тәрбия максатларын күздә тоткан басма тәрбиячеләргә, укытучыларга, сыйныф җитәкчеләренә һәм ата-аналарга тәгаенләнгән.

Книга, подготовленная при поддержке Комиссии при Раисе Республики Татарстан по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих в Республике Татарстан, посвящена приумножению и популяризации наследия выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри. Настоящее издание, выпущенное в воспитательных и учебных целях, предназначено для воспитателей, учителей, классных руководителей и родителей.

УДК 37.018.1
ISBN 978-5-6050160-2-1 ББК 74.9

© Татарское детское издательство, 2024

Просветительское издание

Каюм Насыйри

# Китаб-әт-тәрбия

Каюм Насыри

# Книга о воспитании

Казань 2024

Хөрмәтле хезмәттәшләрем!

Сез кулыгызга алган «Китаб-әт-тәрбия» китабы — татар халкының гасырлар дәвамында туплаган рухи байлыгының бик кадерле бер өлеше. Татар халкының тәрбия тәҗрибәсен, педагогикасын тирәнтен өйрәнгән һәм бөртекләп җыйган мәгърифәтче галим, педагог һәм язучы Каюм Насыйри халыкка аң-белем тарату, аның телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен үстерү юнәлешендә зур эш башкара. Мәгърифәтченең хезмәтләрендә халкыбызның тормыш-көнкүреше, үзара мөнәсәбәте, эчке кичерешләре, тәрбия тәҗрибәсе чагылыш таба, халыкның педагогик мирасына өстенлек бирелә. Тәрбиядә халыкчанлык һәм гуманлылык — К. Насыйриның төп педагогик принцибы. Атаклы мәгърифәтче туплаган әлеге хәзинә игелекле, тырыш, гыйлемле, әдәпле, кешелекле буын тәрбияләүдә гаҗәеп файдалы һәм үтемле, чөнки аның нәсихәтләрендә күтәрелгән мәсьәләләр, гасырлар узуга карамастан, бүген дә әһәмиятле, бүген дә көн үзәгендә. Бу җыентыкның тәрбия эшендә, белем алуга омтылыш булдыруда, гомумкешелек әхлак кагыйдәләрен сеңдерүдә ярдәме бәхәссез. Уку-укыту, тәрбия, аң-белем тарату максатларында куллану өчен чыгарылган әлеге басма һәр укытучының, сыйныф җитәкчесенең, һәр тәрбиячәнең һәм гомумән һәр татар кешесенең өстәл китабына әйләнер, дип ышанабыз.

«Китаб-әт-тәрбия» хезмәте XIX гасырның икенче яртысында К.Насыйри үзе нигез салган әдәби телебездә язылган булуы белән дә кыйммәтле. Үгет-нәсихәтләрнең русчага тәрҗемәсе моннан гасыр ярым элек яшәгән бабаларыбыз сөйләшкән телне яхшырак аңларга ярдәм итә. Китаптагы иллюстрацияләр нәсихәтләргә тирәнрәк төшенергә, аларны җанлырак күзалларга булыша, безне татар теленең бай сурәтләү чаралары дөньясына сәяхәткә дәшә. Бу сәяхәт белем-мәгърифәт тарату, киләчәк буынга үтемле тәрбия бирү эшен камилләштерүдә яңа, кызыклы һәм файдалы сәфәр булсын! Бүгенге буын балаларын нәкъ менә тыйнаклыгы, итагатьлелеге, фикер сөрешенең ачыклыгы белән замандашларын да сокландырган К. Насыйриның бай мирасына таянып тәрбияләсәк иде.

Хәерле сәгатьтә!

*Илсур Һадиуллин,*
*Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры*

Уважаемые коллеги!

В ваших руках «Книга о воспитании» — бесценная часть огромного духовного богатства, накопленного татарским народом на протяжении веков. Учёный-просветитель, педагог и писатель Каюм Насыри, по крупинкам собравший и изучивший педагогический опыт татарского народа, провёл огромную работу по просвещению населения, развитию татарского языка, литературы и культуры. В трудах просветителя отражаются быт, взаимоотношения, внутренние переживания народа, его педагогический опыт, во главу угла ставится педагогическое наследие народа. Народность и гуманность в воспитании — основные педагогические принципы К. Насыри.

Это наследие, собранное выдающимся татарским просветителем, является путеводителем в деле воспитания доброго, трудолюбивого, образованного, вежливого, человечного поколения, поскольку темы, которые поднимаются в написанных более сотни лет назад наставлениях Каюма Насыри, крайне важны и актуальны и в настоящее время. Сборник наставлений станет верным помощником в воспитательной работе, в формировании стремления к обучению, в усвоении общечеловеческих нравственных норм. Мы надеемся, что издание, выпущенное в воспитательных, просветительных и учебных целях, превратится в настольную книгу каждого учителя, каждого классного руководителя, каждого воспитателя и каждой личности.

Труд Каюма Насыри «Книга о воспитании» ценен и тем, что был написан языком, основы которого во второй половине XIX века заложил сам просветитель. Перевод наставлений на русский язык позволит понять значения устаревших слов и выражений, которые были в обиходе полтора века назад. Иллюстрации к каждому наставлению помогут осмыслить напутствия просветителя, оживляя их и приглашая нас в путешествие в мир художественных метафор и ассоциаций. Пусть это путешествие станет новым, интересным и плодотворным шагом в просвещении и воспитании будущих поколений! Хотелось бы воспитать нынешних детей на основе богатого наследия К. Насыри, завоевавшего уважение современников своей скромностью, покорностью, ясностью мышления.

В добрый час!

*Ильсур Хадиуллин,*
*министр образования и науки Республики Татарстан*

# КЕРЕШ СҮЗ

Күренекле татар мәгърифәтчесе, энциклопедист галим, сүзлекләр авторы Каюм Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия» китабына татар халкының буыннан-буынга тапшырылып килгән, тормышның әхлакый нигезен тәшкил иткән кагыйдәләр, үгет-нәсихәтләр тупланган. Әлеге үгет-нәсихәтләр, үз-үзеңне тоту нормалары, бер гасырдан артык вакыт узса да, актуальлеген һич югалтмаган. Киресенчә, алар бүген тагын да эчтәлеклерәк, мәгънәлерәк яңгырый.

«Китаб-әт-тәрбия» җыентыгы XIX гасыр ахырында берничә тапкыр басыла. Китапның халыкчан тел белән язылган булуы, балаларга үтемле тәрбия бирүе бу басманың популярлыгында мөһим роль уйный. Сез бүген кулыгызга алган китапта Каюм Насыйри хезмәтенең теле мөмкин кадәр үзгәрешсез тәкъдим ителә, бу исә халкыбызның XIX йөздә ничек сөйләшкәнен күзалларга, телебездәге үсеш-үзгәрешләрне күрергә, тоярга, чагыштырырга һәм хәтта сүз байлыгыбызны арттырырга мөмкинлек бирә. Нәсихәтләрнең русчага тәрҗемәсе басманың куллану даирәсен киңәйтер, татарча оригинал текст белән чагыштырып, шул чордагы татар әдәби телен күзалларга һәм аны яхшырак аңларга ярдәм итәр, дип уйлыйбыз. Ә китаптагы матур, гыйбрәтле, заманча иллюстрацияләр атаклы Каюм бабай нәсихәтләренең асылын тирәнрәк аңларга этәргеч булып тора.

Кулыгыздагы китап «Китаб-әт-тәрбия» комплексының бер өлешен тәшкил итә. Әлеге комплекс басма китап һәм сайтны берләштерә. Каюм Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия» китабында тәкъдим ителгән үгет-нәсихәтләрне www.каюмнасыйри.рф сайтыннан да укырга мөмкин. Бу сайтта бөек мәгърифәтче турында да тулырак мәгълүмат таба аласыз. Мондый комплексны мәктәпләрдә дәрес вакытында да, сыйныфтан тыш чараларда да кулланырга була. Ата-бабаларыбыздан калган кыйммәтле бай мирасыбызны өйрәник һәм саклыйк!

# ВВЕДЕНИЕ

Книга выдающегося татарского просветителя, учёного-энциклопедиста, автора многих словарей Каюма Насыри «Книга о воспитании» («Китаб-әт-тәрбия») является сводом правил морали, наставлений, которые передаются из поколения в поколение и составляют нравственную основу татарского народа. Труд просветителя был написан более века назад, при этом нравоучения, нормы поведения, изложенные им, не утратили своей актуальности и по сей день. Наоборот, сегодня они порой звучат более содержательно и осмысленно.

Сборник наставлений «Книга о воспитании» вышел в свет в конце XIX века и неоднократно переиздавался. Важную роль в популярности издания сыграло то, что книга в своё время была написана на близком для народа языке и состоит из наставлений, которые представлены в доступной для детей форме. В книге, которую вы сегодня держите в руках, язык Каюма Насыри сохранён в наиболее близком к оригиналу виде, что позволяет представить, как разговаривали в XIX столетии, увидеть, почувствовать, сравнить изменение и развитие татарского языка, и в то же время обогатить лексику. Мы считаем, что перевод на русский язык расширит аудиторию книги, а сопоставление с оригиналом на татарском языке поможет вникнуть в особенности татарского литературного языка того периода. Красивые, поучительные, современные иллюстрации облегчат работу при разъяснении детям наставлений знаменитого Каюма Насыри, помогут лучше освоить суть нравоучений и проникнуться ими.

Настоящая книга является частью комплекса «Китаб-әт-тәрбия», который объединяет печатное издание и сайт. Наставления, представленные в «Книге о воспитании», можно прочитать на сайте www.каюмнасыйри.рф в виде электронной книги. Здесь вы также найдёте более полную информацию о великом просветителе. Такой комплекс можно использовать в школах как во время уроков, так и во внеклассных мероприятиях. Изучим и сохраним бесценное наследие наших предков!



*Беренче тәрбия*

##ҺӨНӘР — ЫШАНЫЧЛЫ БАЙЛЫК

Бер хәким балаларга шундый нәсихәт бирде: «Әй җаннарым, угланнарым, нәсихәтне ишетегез — һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкенә һәм байлыгына ышанырга ярамас. Алтын-көмеш — сәфәр кешесенә хәтәр; йорт-йир кешесенә дә хәтәре бар: я угры алып китәр, яки утка янып китәр. Әмма һөнәр — бер агым судыр һәм ышанычлы дәүләтдер. Һөнәр иясе мөлкәтсез калса да, кайгысы юк. Инде, әй угыл, бу урында максат бер хикәят түгел. Син дә шулай ук һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән».

*Наставление первое*

## РЕМЕСЛО — НАДЁЖНОЕ БОГАТСТВО

Один мудрец так поучал детей: «О милые дети, послушайтесь моего совета — учитесь ремеслу. Не стоит полагаться на имущество и деньги. Золото и серебро — лишь опасность для путника, а дома богатства могут отнять грабители или пламя пожара. Ремесло же надёжно и неиссякаемо, как источник. Умелец не пропадёт, даже если лишится всех богатств своих. Верьте, дети мои, это не пустые разговоры. Постигайте же ремёсла, углубляйте знания, совершенствуйте характер».



*Икенче тәрбия*

## ҮЗЕҢНЕ ЯМАНЛАГАН КЕШЕНЕ МАКТА

Мәшаихләрдән берсенә бер адәм шикаять кыйлды ки: «Фәлән кеше, минем бозык эшләремне сөйләп, фәлән йирдә мине яманлаган», — диде. Ул мәшаих әйтте ки: «Син аның яхшы эшләрен сөйләп, аны оятлы ит», — диде. Бу дәхи сиңа бер тәрбиядер.

Әй угыл, һәрбер хикәяттән бер мәгънә фәһем иткәйсән ки, аңсыздан, берәү сине бер йирдә яманлаган булса, аңар каршы син аны макта. Шаять ки, ул үзе дә, адәм булса, инсаф итәр вә оялыр...

*Наставление второе*

## ПОХВАЛИ ТОГО, КТО СКАЗАЛ О ТЕБЕ НЕГОДНОЕ

Некто пожаловался мудрейшему из старцев: «Такой-то человек там-то порочил меня». Старик сказал ему на это: «А ты поведай людям о его добрых делах, пусть ему станет совестно».

Слова эти и тебе наука, о сын мой. Постарайся извлечь пользу из любой истории, и если кто-нибудь по глупости скажет о тебе плохое, ты, напротив, похвали его, авось возьмётся за ум и устыдится...


2+2=
F(x)=5x²/3+7x²+K

*Өченче тәрбия*

## ГЫЙЛЕМ ҺӘМ МӘГЪРИФӘТ БУЙГА ҺӘМ КЫЯФӘТКӘ КАРАМЫЙ

Бер падишаһның берничә улы булып, араларыннан берсе зәгыйфь, кыска буйлы, кечкенә иде. Башкалары озын буйлы, матур йөзле иде, әмма аталары ул улына нәфрәт белән, кимсетеп карый иде. Бу улы бер зиһен иясе һәм мәгърифәтле бала иде. Ул әйтте: «Әй ата, гакыллы тәбәнәк надан озыннан яхшырак түгелме? Һәрнәрсәнең кыйммәте күләменә карап йөрмәйдер. Мунча ташы бик эре, тик йөге — бер тәңкә, энҗе бик вак, мыскалы — ун тәңкә», — диде. Аталары һәм дәүләтнең зур кешеләре барчасы көлештеләр һәм «бәрәкалла» дип хупладылар...

Әй угыл, гыйлем һәм мәгърифәт дигән нәрсә буйга вә кыяфәткә карап булмайдыр.

*Наставление третье*

## УМ И ЗНАНИЯ НЕ ЗАВИСЯТ ОТ РОСТА И ВНЕШНОСТИ ЧЕЛОВЕКА

Было у одного падишаха несколько сыновей. Все они были высоки, статны, хороши собой, лишь один выделялся хилым телосложением и невысоким ростом, и отец ненавидел и презирал неказистого отпрыска. Однако этот его сын был умён и прекрасно образован. «О отец, — сказал он однажды, — умный человек маленького роста лучше большого невежды, не правда ли? Ведь ценность вещей не определяется их размерами. Камни, что используют для бань, велики, но целый воз их можно купить всего за одну монетку. Жемчуг так мал, но каждый его золотник стоит десять золотых». Отец и сидевшие в зале государственные мужи одобрительно засмеялись в ответ...

О сын мой, ум и знания не зависят от роста и внешнего вида человека.



*Бишенче тәрбия*[1]

## ТИЛЕ КҮЗСЕЗЛӘРДӘН, НАДАННАРДАН ГЫЙБРӘТ АЛ

Локман хәкимнән сорадылар: «Син хикмәтне кемнән үгрәндең?» — диделәр. Әйтте: «Күзсез кешеләрдән үгрәндем, чөнки алар аяк басасы урынны күрмәенчә аяк басалар», — диде...

Әй угыл, монда сиңа тәрбия шулдыр ки, Локман хәкимнең сүзен яхшы фәһем итеп кара, ягъни ул: «Күзсезләр, аяк басасы урынны күрмәенчә, я абыналар, яки төртеләләр, яки егылалар, шулай ук аңы юк кешеләр вә наданнар сүзнең урынын белмәй сөйләшәләр, вә ахырын уйлап сөйләшмәйләр. Аларның наданлыкларын күрдем дә хәким булдым», — диде.

*Наставление пятое*

## ПОСТИГАЙ МУДРОСТЬ, НАБЛЮДАЯ НЕВЕЖД И ГЛУПЦОВ

Когда премудрого Лукмана спросили: «Кто научил тебя мудрости?», он ответил: «Слепцы, которые не ведают, куда ступает их нога...»

Хорошенько поразмысли над словами мудрого Лукмана, о сын мой, ибо глупцы и невежды бредут во мраке и, подобно слепым, спотыкаются, наталкиваются на препятствия, падают. Они бросаются словами, не думая о последствиях. Потому мудрец и сказал, что постиг мудрость, наблюдая невежд и глупцов.

---

[1] Нәшрияттан: 4, 32, 47, 101, 109, 110 нчы тәрбияләр ниндидер сәбәпләр белән Каюм Насыйриның беренче (гарәпчә) басмаларына да кертелмәгән булган.
От издательства. В издания Каюма Насыри, вышедшие на основе арабской графики, наставления 4, 32, 47, 101, 109, 110 по какой-то причине не были включены.



*Алтынчы тәрбия*

## НАДАН, ТИЛЕ ЯНЫНДА ЙӨРСӘҢ, ҮЗЕҢ ДӘ ШУҢА ОХШЫЙ БАРАСЫҢ

Олуглардан бер адәм үзенең углын бер галим остазга тәгълим вә тәрбия өчен тапшырды. Вә әйтте ки: «Әй остазе камил, ошбу баланы тәрбия кыйл вә укыт ки, галим вә гакыйл булсын», — диде. Берничә вакыт бу баланы остаз тәрбия кыйлды вә укытты. Әмма һичбер гыйлем әсәр кыйлмады. Ул баланы атасына кайтарып йибәрде. Әйтте: «Бу бала һичбер белемгә сәләтле түгелдер, хәтта үземне диванә кыйлды», — диде...

*Наставление шестое*

## ЕСЛИ ПОВАДИШЬСЯ С ГЛУПЦОМ, НЕВЕЖДОЙ, САМ СТАНЕШЬ ПОХОЖИМ НА НЕГО

Один почтенный человек отдал сына учёному наставнику для воспитания и обучения. И сказал: «О лучший из учителей, воспитай это дитя и дай ему знания, пусть станет мудр и учен». Наставник занимался с мальчиком, учил его наукам, но из этого ничего не вышло. И он отвёл его назад к отцу, сказал: «Ребёнок этот настолько глух к наукам и туп, что я чувствую, как сам глупею, когда учу его».



*Җиденче тәрбия*

## КЕШЕ ИМИНЛЕК ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕҢ КАДЕРЕН БЕР МИХНӘТКӘ ДУЧАР БУЛГАЧ БЕЛӘ

Бер падишаһ, диңгездә көймәдә сәфәр кыйлганда, моңарчы көймәгә утырганы булмаган бер егетне күрде. Бу егетнең көймәдәге мәшәкатьне, кыенлыкларны күргәне юк икән. Куркып еглап утыра, дер-дер калтырый. Никадәр юатып карасалар да, еглаудан һаңүз туктамай. Падишаһ та хафага төшә. Анда бер хәким бар иде, ул әйтте: «Әй әфәнделәр, әгәр боерсагыз, мин бер хәйлә кыйлаем: шаять, сабыр итәр», — диде. Падишаһ әйтте: «Белгәнеңне эшлә», — диде. Хәким әмер бирде. Бу егетне бәйләп дәрьяга аттылар, бер-ике мәртәбә чумдырып, янә көймәгә алдылар. Егет, үлемнән терелеп кайткан кебек хәйран булып, бер дә дәшмәенчә утырды, күңеле тынычланды. Падишаһ моны бик ошатып, хәкимгә әйтте: «Я хәким, монда ни хикмәт бардыр?» Хәким әйтте: «Ул егет әүвәл көймәнең мәшәкатен һәм су сәфәрен күрмәгән, янә суга батуны һәм көймәдә сәламәт йөрүнең кадерен белгәне юк, имеш», — диде.

Монда сиңа тәрбия шулдыр, әй угыл, кеше гафиятенең вә сәламәтлекнең кадерен бер михнәткә дучар булгач беләдер.

*Наставление седьмое*

## ЧЕЛОВЕК НЕ В СИЛАХ РАДОВАТЬСЯ СВОЕМУ ЗДОРОВЬЮ И БЛАГОПОЛУЧИЮ, ПОКА СУДЬБА НЕ ПОШЛЁТ ЕМУ ИСПЫТАНИЕ

Один падишах, путешествуя по морю, обратил внимание на юношу, который впервые попал на корабль и не был знаком с трудностями, столь обычными в плавании. Он всё время плакал, дрожа от страха. И сколько его ни успокаивали, не переставал плакать. Падишаха это весьма огорчало. Мудрец, бывший в его свите, сказал: «О повелитель, если позволишь, я уйму юношу. Мне известна хитрость, которая научит его выдержке». «Поступай как знаешь», — ответил падишах. Мудрец распорядился связать юношу, бросить за борт, окунуть раза два и поднять на корабль. Почувствовав себя воскресшим из мертвых, он сидел теперь тихо. Падишаху это понравилось, и он спросил: «В чём же твоя хитрость, мудрец?» Тот ответил: «Этот юноша никогда не ходил в море, не знал, как тонут люди, а потому не умел радоваться благополучному плаванию».

Знай же, сын мой, часто человек не в силах радоваться своему здоровью и благополучию, пока судьба не пошлёт ему испытание.



*Сигезенче тәрбия*

## УРЫНСЫЗ САРАНЛЫК — ФАЙДАСЫЗ

Бер падишаһ углының атасыннан калган күп хәзинәсе бар иде. Киң күңеллелек вә җумардлык кулын ачты, вә үзенең гаскәр халкына вә үз дәүләте кешеләренә ниһаятьсез хәзинәләр түкте. Бервакытны бер ахырын уйламаучы киңәшчесе нәсихәт әйтте: «Әй шаһзадә, элеккеге падишаһлар бу хәзинәне иҗтиһад белән хасил иткәннәрдер, вә бер мәслихәт өчен хәзерләгәннәрдер. Син азрак кысыбрак тот, вакыйгалар алдадыр, хәзинәнең хаҗәт вакыты килер», — диде. Шаһзадә аның мәслихәтен мәгъкуль күрмәде... «Ни була, ашармын, эчәрмен, бирермен, мин ул хәзинәгә каравылчы булганым юк», — диде.

Әй угыл, урынсыз саранлык кыйлырга да ярамый, урынсыз җумардлык та ярамый.

*Наставление восьмое*

## НЕ ПРОЯВЛЯЙ СКУПОСТЬ ТАМ, ГДЕ ОНА НЕУМЕСТНА

Сыну одного падишаха досталось богатое наследство. Был он добр и щедр, а потому великодушно одарял золотом воинов и государственных мужей, которые ему служили. Однажды один из его советников, забыв об осторожности, решил предостеречь его: «О шахзаде, прежние повелители собирали сокровища с большим усердием, думая употребить их для пользы. Не будь же столь расточителен, всё у тебя впереди, придёт время, и понадобятся ещё твои богатства». Шахзаде не понравились его слова... «Ну так что же? — возразил он. — Буду есть, пить и делиться тем, что имею. Я сокровищам не сторож».

Ни к чему, сын мой, проявлять скупость там, где она неуместна, но и неуместная щедрость тоже вредна.



*Тугызынчы тәрбия*

## ҮЗ КӨЧЕҢ БЕЛӘН ТАПКАН БЕР ТИЕНЕҢ ЧИТ КУЛ БИРГӘН МЕҢ ТИЕННӘН БӘРӘКӘТЛЕРӘК

Ике борадәр бар иде. Бере падишаһ хезмәтендә булып гомер кичерер иде. Бере үзенең кул көче белән табыш итеп тереклек кыйлыр иде. Бервакытны ул падишаһ хезмәтендәге бай туганы әйтте: «Әй туганым, ник падишаһ хезмәтенә кермәйсән? Таки каты хезмәтләрдән котылыр идең», — диде. Ул туганы әйтте: «Син ник кул көчең белән тереклек кыйлмайсән? Таки хезмәт хурлыкыннан вә кимсетелүдән котылыр идең. Хәкимнәр әйткәннәрдер ки, үз икмәгеңне ашап өеңдә утыруың, кеше хезмәтендә алтын кәмәр баглавыңнан артыгракдыр...»

Үз көчең белән тапкан бер тиенең кеше көче белән хасил булган мең тиеннән бәрәкәтлерәкдер.

*Наставление девятое*

## КОПЕЙКА, ДОБЫТАЯ СВОИМ ТРУДОМ, ДОРОЖЕ ТЫСЯЧИ КОПЕЕК, ПОЛУЧЕННЫХ ИЗ ЧУЖИХ РУК

Жили два брата. Один состоял на службе у падишаха. Другой добывал себе на жизнь физическим трудом. Богатый брат, служивший у падишаха, спросил однажды бедного: «Почему не идёшь на службу к падишаху? Тебе не пришлось бы делать столь тяжёлую работу». Тот ответил: «А почему ты не живёшь трудом? Это избавило бы тебя от позора и многих унижений. Ведь недаром мудрецы говорили: лучше сидеть дома и есть свой кусок хлеба, чем кому-то прислуживать в расшитом золотом кушаке...»

Копейка, добытая своим трудом, дороже тысячи копеек, полученных из чужих рук.



*Унынчы тәрбия*

## ӘҢГӘМӘГӘ УРЫНСЫЗ ТЫГЫЛУ — ӘДӘПСЕЗЛЕК

Нуширван падишаһ сараенда бер груһ хәкимнәр бер мәслихәт хосусында сөйләшеп утырырлар иде. Ул мәҗлестә Бөзәрҗөмһөр һәм бар иде. Әмма ул һич сүз дәшмәенчә сөкүт кыйлып утырыр иде. Әйттеләр: «Я, Бөзәрҗөмһөр, син бу хосуста безнең сүземезгә бер дә катышмайсән», — диделәр. Бөзәрҗөмһөр әйтте: «Вәзирләр — табиблардыр: авыру түгел кешегә дару бирмәйләр. Мин күрәмен ки, сезнең фикерегез растдыр, бу тәкъдирдә минем катышуымның хикмәте бер дә юкдыр», — диде.

Әй угыл, Бөзәрҗөмһөрдән сиңа тәрбия шулдыр ки, хәкимнәр булып хәкимнәр урынсыз йирдә кеше сүзенә катышмадылар. Кешенең сөйләшә торган сүзен кисеп сүз әйтмәк — начар холыкдыр. Әгәр кеше сүзенә катышмакчы булсаң, мәҗлесдәшләрең сүздән туктаган арада сүзгә катышкайсән.

*Наставление десятое*

## НЕУМЕСТНОЕ ВМЕШАТЕЛЬСТВО В БЕСЕДУ — ДУРНОЙ ТОН

Во дворец Нуширвана падишаха собрали на совет мудрецов. Был среди них и Бозаржумхур. Во время разговоров он хранил молчание. Его спросили: «Почему ты, Бозаржумхур, не принимаешь участия в нашей беседе?» Мудрец ответил: «Визири — те же лекари: здоровому человеку лекарство не дают. Я вижу, что вы рассуждаете совершенно верно и моё вмешательство излишне».

О сын мой, Бозаржумхур дал тебе хороший урок: даже мудрецы не встревают в разговор без надобности. Прерывать человека на полуслове — и вовсе плохая привычка. Если хочешь принять участие в разговоре, дождись, когда умолкнут твои собеседники.



*Унберенче тәрбия*

## ИГЕЛЕК ҺӘМ ЙОМШАКЛЫК БЕЛӘН МӘМЛӘКӘТЛӘР ЯУЛАНА

Искәндәр Румидан сорадылар: «Мәшрикъ вә Мәгъриб илләрен ничек итеп алдың. Элеккеге падишаһлар никадәр гаскәр вә акча, вә хәзинә түгеп тә алалмаганнар иде», — диделәр. Искәндәр әйтте: «Аллаһ Тәгаләнең ярдәме белән алдым. Һәр мәмләкәтне алдым, халкын рәнҗетмәдем. Вә элгәре падишаһларны изгелектән гайре нәрсә белән зикер кыйлмадым», — диде.

Әй угыл, имде күрдең, ниндәен тәрбияле кешеләр бар, имеш. Хилем вә йомшаклык белән бөтен мәмләкәтне яулап алалар; хилем вә йомшак сүзле булырга тиеш: гәрчә дошманың булса да, изгелектән гайре зикер кыйлмагайсән.

*Наставление одиннадцатое*

## ДОБРОТА И КРОТОСТЬ БЕРУТ ГОРОДА

Александра Македонского спросили: «Как удалось тебе добиться покорности на Востоке и Западе? Прежние правители не жалели ни войск, ни сокровищ, а не смогли завоевать столько стран». Александр ответил: «На всё воля Всевышнего. Я брал страны, но не обижал народ. А прежних правителей поминал только добром».

О сын мой, видишь, сколь могуч воспитанный человек? Доброта и кротость берут города; надо быть добрым и снисходительным ко всем, остерегайся говорить дурно даже о своих врагах.



*Уникенче тәрбия*

## ШИК-ШӨБҺӘ БЕЛӘН КЕШЕ ӨСТЕНӘ ГАЕП ТАГУ — ХАТА

Олуглардан берәү бер падишаһтан сорады: «Фәлән дәрвиш хакында ни әйтәсең? Кайберәүләр аны хурлыйлар», — диде. Ул падишаһ әйтте: «Мин тышкы яктан караганда гаеп күрмәймен, әмма эче, күңеле — билгесездер. Шуңа хөкем итә алмаймын», — диде.

Әй угыл, фәкать үзеңнең гөманың белән генә: «Бу кеше фәләндер», — дип, кеше өстенә гаеп тагу — хатадыр. Моны «сүи зан» диярләр, бу — хәрам эш, моннан саклан.

*Наставление двенадцатое*

## ОШИБКА — ОСУЖДАТЬ ЧЕЛОВЕКА, ПОЛАГАЯСЬ ТОЛЬКО НА СВОЁ МНЕНИЕ

Один царедворец спросил падишаха: «Что ты скажешь о дервише таком-то? Некоторые говорят о нём плохое». Падишах ответил: «На сторонний взгляд в нём нет ничего предосудительного, а что у него за душой — не видно. Я не могу судить о том, чего не вижу».

О сын мой, было бы ошибкой осуждать человека, полагаясь только на своё мнение. Это очень скверно. Избегай поспешных суждений.



*Унөченче тәрбия*

## АХИРӘТТӘ ЙӨЗЕҢӘ ЧЫГАРЛЫК ГАМӘЛЛӘР ЭШЛӘМӘ

Шәех Сәгъди димешдер ки: «Хаждa Габделкадыйр Гилянине күрдем. Кәгъбәгә башын куеп ятмыш әйтәдер ки: «Әй Ходавәндә, гафу кыйл! Әгәр гафу итмәсәң, кыяматтә күзсез итеп каберемнән кубар: изге кешеләр алдында оятлы булмагай идем!» — дидер».

Әй угыл, дөньяда бер кечкенә генә гаебеңне дә кешеләр күзенә күрсәтергә ояласың. Кыяматтә, пәйгамбәрләр, изгеләр һәм бөтен дөнья халкы күз алдында гаепләреңне һәм гөнаһларыңны йөзеңә бәрсәләр, анда качарга урын юк. Инде сиңа тәрбия будыр ки: ахирәттә йөзеңә киләсе гаепне эшләмә. Габделкадыйр Гиляни кебек изге кешеләр шулкадәр курыкса, сиңа, миңа — ни сан?! Иман китермәк фарыздыр.

*Наставление тринадцатое*

## НЕ СОВЕРШАЙ ПОСТЫДНЫХ ПОСТУПКОВ

Вот что рассказал мудрый Саади: «Видел в Мекке Габделькадыра Гиляни. Вперив взор в Каабу, он причитал: «О Всевышний, прости меня! Если не простишь, в Судный день исторгни меня из могилы незрячим, дабы не видеть себя опозоренным перед святыми».

О сын мой! В миру стыдишься перед людьми даже крохотного своего проступка. А ежели в Судный день все твои прегрешения предстанут перед святыми и пророками, тебе и спрятаться будет негде от позора. Пусть это послужит тебе уроком: не совершай постыдных поступков. Ведь если даже такие праведники, как Габделькадыр Гиляни, страшатся Судного дня, что остаётся делать мне и тебе? Нужно быть праведным в миру.



*Ундүртенче тәрбия*

## ФӘКЫЙРЬЛӘРНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ, АЛАРНЫ ЯКЫН ИТҮ — ӘҖЕРЛЕ

Изгеләрдән бер адәм бер падишаһны төшендә күрде — оҗмахта утырыр. Вә дәхи бер фәкыйрь суфыйны күрде — җәһәннәмдә газапта, имеш. Сорады: «Бу падишаһ бу дәрәҗәне ни белән тапты да, бу фәкыйрь суфый бу түбәнлеккә ни сәбәпле төште? Без моның хилафын гөман кыйладыр идек», — диде. Әйттеләр: «Падишаһ фәкыйрьләрне вә дәрвишләрне сәүгән өчен оҗмахлык булды. Әмма бу фәкыйрь, падишаһларга якынлыгы сәбәпле, җәһәннәмлек булды», — диделәр.

Әй угыл, залимнәр таифәсенә вә нәфесенә золымлык кыйлгучыларга якынлык дәхи мөселман эше түгелдер.

*Наставление четырнадцатое*

## ДОБРОЕ ОТНОШЕНИЕ К НИЩИМ, НУЖДАЮЩИМСЯ ВОЗНАГРАДИТСЯ

Одному праведнику привиделось во сне, будто бы падишах попал в рай, а старый дервиш, целыми днями не сходящий с молитвенного коврика, мучается в аду. «За что же падишаху такая честь, и чем провинился благочестивый старец? — спросил он.— Вроде всё должно быть наоборот?» Ему ответили: «Падишах попал в рай за то, что приютил у себя нищих дервишей, а тот несчастный оказался в аду за то, что жил во дворце падишаха».

О сын мой! Не стоит примыкать к тиранам и к тем, кто творит несправедливости и потакает своим прихотям.



*Унбишенче тәрбия*

## КАРА КҮҢЕЛГӘ ҮГЕТ-НӘСИХӘТ ҮТМИ

Юнан вилаятендә бер кәрванны талап, хисапсыз малларны алып киттеләр. Сәүдәгәрләр бик еглаштылар, Аллаһ Тәгаләдән ярдәм телəделәр. Ни файда? Ул кәрван эчендә Локман хәким бар иде. Берәү әйтте: «Я хәким, ул угрыларга берничә хикмәт кәлимәләре әйтче, таки малларымызны кайтарып бирсеннәр», — диделәр. Локман әйтте: «Аларга хикмәтнең тәэсире тимәс, — диде. — Ягъни кара күңелгә хикмәт вә вәгазь әсәр итмәс, ташка кадак кагып булмайдыр», — диде...

Әй угыл, вәгазьләр бар, насихләр бар, бәгъзесенең вәгазьләре вә нәсихәтләре әсәрле түгелдер. Вәгазь әсәр итмәгәнлек күп вакытны вәгазь иткученең пәрһиз түгеллегеннәндер.

*Наставление пятнадцатое*

## ЕСЛИ СОВЕСТЬ ЧЕРНА, ДОБРОЕ НАСТАВЛЕНИЕ БЕССИЛЬНО

В греческой провинции воры напали на караван и унесли несметные богатства. Купцы громко стенали и молили Аллаха помочь им. Но что толку? Случилось быть там и мудрому Лукману. «О мудрейший, — обратился к нему один из купцов, — скажи свое вразумляющее поучительное слово, пусть воры вернут наше добро». Лукман ответил: «Наставление здесь бессильно. Того, чья совесть черна, не пронять ни колдовством, ни добрым словом, как нельзя вбить гвоздь в камень».

О сын мой, есть наставления, есть проповедники, но наставления и проповеди некоторых бездейственны. Беседуя о важном, надо уметь правильно выбрать слушателя, время и место разговора.



*Уналтынчы тәрбия*

## АКЫЛЛЫ БӘНДӘ ӨЧЕН АДЫМ САЕН ГЫЙБРӘТ БАР

Локман хәкимнән сорадылар: «Син әдәпне кемнән үгрәндең?» — диделәр. Локман әйтте: «Әдәпсезләрнең әдәпсезлеген күреп, үземә килешмәгән кебек булды да, һаман андаен фигыльләрдән саклана килдем, әдәпле булдым», — диде.

Әй угыл, гакыллы балага атлам саен гыйбрәтләр бар, вәгазьләр бар, мәгърифәт хасил итә күр.

*Наставление шестнадцатое*

## ДЛЯ УМНОГО ЧЕЛОВЕКА ВОКРУГ ОЧЕНЬ МНОГО ПОУЧИТЕЛЬНОГО

Мудрого Лукмана спросили: «У кого учился ты благовоспитанности?» Лукман ответил: «Я наблюдал развязность невеж и избегал повторять то, что мне не нравилось в них, и так стал воспитанным.

О сын мой, для того, кто умён, вокруг столько поучительного, постарайся же извлекать из этого пользу.



*Унҗиденче тәрбия*

## КОРСАКНЫ КҮП ТУТЫРУ ФАЙДАГА ТҮГЕЛ

Хикәят кыйлынмышдыр ки: бер дәрвиш кичен бик күп тәгам ашап, сәхәргә кадәр бертуктаусыз намаз укый, имеш, диделәр. Моны бер гакыл иясе ишетеп әйтте: «Кашки бичара ярты кадак икмәк ашап ятып йокласа, күпкә яхшырак булыр иде».

Әй угыл, корсакны күп тутырмак хикмәткә мөнафидер.

*Наставление семнадцатое*

## ЧРЕВОУГОДНИЧЕСТВО ПРОТИВНО РАЗУМУ

Рассказывают, что один дервиш на удивление зевакам съел вечером двести фунтов хлеба и потом всю ночь напролёт провёл в молитвах. Услышав это, один умный человек заметил: «Лучше бы он съел полфунта, тогда ночью смог бы уснуть».

Чревоугодничество, о сын мой, не приносит пользы.



*Унсигезенче тәрбия*

## ҖАН ИЯЛӘРЕННӘН ГЫЙБРӘТ АЛЫП, ЗИКЕР-ТӘСБИХ ӘЙТЕП ЯШӘ

Шәех Сәгъди хикмәт кыйлмыштыр ки: бер сәфәремездә бер кичнең эчендә уйганып күрдем ки: кәрван эчендә бер адәм бар, имеш. Бөтен төн, бәет вә шигырь әйтеп, һич йокламаенча кичне уздырды. «Бу ни хәл?!» — дип сорадым. Әйтте ки: «Былбылларны күрдем ки: агачтан агачка очып, налә вә фәган (аһ-зар) кыйлалар. Киекләр таулардан налә вә фәган кыйлалар. Бакалар суда налә вә фәган кыйлалар. Хайваннар урманнардан налә вә фәган кыйлалар. Шундый фикер кыйлдым ки: һәммә хайваннар, киекләр, кошлар йокламаенча зикер-тәсбих әйткәндә икән, үземнең гафләттә булмагымны кешелек дип саймадым», — диде.

*Наставление восемнадцатое*

## БЕРИ ПРИМЕР ОТ ВСЕХ ЖИВЫХ СУЩЕСТВ И БЛАГОСЛОВЛЯЙ ВСЕВЫШНЕГО

Во время одного из своих путешествий мудрый Саади неожиданно проснулся посреди ночи. Он несказанно удивился, увидев своего товарища сидящим поодаль и читающим стихи и песни. «Что это значит?» — спросил Саади. Спутник его ответил: «Увидел я соловьёв. Перелетая с ветки на ветку, они поют томными голосами. В горах горестно трубят звери, стонут в болотах лягушки. Гомон стоит от их голосов в природе. И подумалось мне: не грешно ли спать, когда всё живое вокруг творит молитвы?»



*Унтугызынчы тәрбия*

## ДӘРВИШКӘ ЗИННӘТ КИЛЕШМИ

Бик озак заманнар бер урманда үлән вә яфрак белән тәрбияләнеп тереклек кыйлгучы бер дәрвиш бар иде. Бер падишаһ ул дәрвишкә хәлен белергә барды. Әйтте: «Я шәех, әгәр мәслихәт күрсәң, шәһәрдә тор, синең өчен урын хәзерләем, тыныч вә рәхәт гыйбадәт кыйлып ятыр идең», — диде. Дәхи дә синең бәрәкәтле нәфесең белән файдаланыр идек. Вә һәм синең изге гамәлләреңә безләр дә иярер идек, диде. Дәрвиш кабул итмәде. Дәүләтнең зур кешеләре падишаһка әйттеләр: «Мәслихәт шулдыр ки, берничә көннәргә ул дәрвишне шәһәргә китереп, бераз кунак итеп караек, кәефенә хуш килеп, бәлки, торырга да разый булыр», — диделәр. Бәс, теге дәрвишне шәһәргә чакырып китерделәр, бер сарайда үзенә хас бер урын хәзерләделәр. Анда шундый гүзәл вә хозур ки, әгәр мәет керсә дә хәят табар. Падишаһ ул дәрвишнең хезмәтенә бер чибәр йөзле кәнизәк йибәрде, янә гүзәл сыйфат бер егет йибәрде. Аннан соң ул дәрвиш ләззәтле ризыкларны татып карый башлады. Ләтыйф вә йомшак киемнәрне кия башлады. Вә татлы эчемлекләр белән, вә хуш исле җимешләр белән тәрбияләнә башлады. Вә кәнизәкнең гүзәллегенә тамаша кыйлып, күз сала башлады. Бервакытны падишаһ ул

дәрвишне күрмәгә карар кыйлды. Килеп күрде ки, дәрвишемез элгәреге дәрвишлек сыйфатыннан чыкмыш; куллары агармыш, йөзләре кызармыш, үзе вә нәфесе симермеш — җефәк мендәрләргә таянмыш, ай йөзле бер кәнизәк хезмәтенә тормыш, тависдай бер егет баш очында җилпәзә тотмыш. Падишаһ хәйран булды. Әйтте: «Бу ике таифәне, ягъни голяманы вә дәрвишләрне мин дуст тотадыр идем», — диде. Бер вәзир әйтте: «Әй падишаһым, голямага алтын бир, таки гайреләр һәм галим булырга җөрьәт итсеннәр. Дәрвишләргә шундаен нәрсә бир ки, урыннарында дәрвиш булып калсыннар», — диде, ягъни ләззәти дөньядан алар юнәлеш алмасыннар, димәкдер.

*Наставление девятнадцатое*

## РОСКОШЬ — НЕ УДЕЛ ОТШЕЛЬНИКОВ

В одном лесу много лет жил отшельник. Пищей ему служили травы и листья. Однажды падишах той страны решил поклониться отшельнику и отправился в лес. «О старец, — сказал он, — если хочешь, живи в городе, я велю приготовить тебе обитель, будешь молиться целыми днями, не думая ни о чём другом.

А мы бы пользовались всеочищающим дыханием твоим, приобщались бы к твоим священным молитвам». Но отшельник не соглашался. Тогда визирь сказал: «Не следует ли позвать старца на несколько дней? Если ему понравится в городе, останется жить».

Отшельника доставили в город и отвели ему место в одном из дворцов. И была эта обитель до того приятной, что окажись в ней мёртвый — и тот ожил бы от восхищения. Прислуживать старцу были приставлены хорошенькая рабыня и прекрасный юноша. Мало-помалу пристрастился отшельник к изысканным яствам, сменил грубое рубище на роскошные мягкие одежды, а там уж и вовсе кроме душистых, сладких плодов ничего не стал признавать. Теперь он частенько поглядывал на невольницу, заметив, как она хороша собой.

Однажды падишах зашёл проведать святого старца, смотрит, а перед ним совсем другой человек: руки белы, лицо румяно, развалился на шёлковых подушках, ему прислуживает невольница с лицом, подобным луне, а прекрасный юноша стоит в изголовье с опахалом. Падишах очень удивился и сказал: «Я с одинаковым почтением относился к мудрецам и отшельникам». «О мой падишах, — возразил на это один из придворных, — не жалей для учёных ни золота, ни других благ, чтобы и другим хотелось заниматься наукой. А что до отшельников, то придумай что-нибудь иное, роскошь — не их удел».



*Егерменче тәрбия*

## ТОРМЫШТА КАНӘГАТЬ БУЛЫП, ГЫЙЛЕМ ҖЫЙ

Мисыр шәһәрендә ике әмирзадә бар иде. Берсе гыйлем үгрәнде, берсе мал казганды, бай булды. Ул берсе голяма булды, бу берсе Мисыр хакиме булды. Бәс, бу бай булганы галим булганына кимсетү күзе белән карар иде вә әйтер иде: «Мин солтанлыкка ирештем, син һаман бер ноктада торасән», — диде. Галим әйтте: «И туганым, Аллаһ Тәгаләгә шөкер итмәк минем тарафымдадыр, чөнки мин пәйгамбәр мирасын таптым, әмма син фиргавен мирасын алдың», — диде.

Әй угыл, бу кыйссадан сиңа тәрбия шулдыр ки, канәгать кирәк. Гыйлем, әлбәттә, пәйгамбәр мирасыдыр.

*Наставление двадцатое*

## БУДЬ ДОВОЛЕН ЖИЗНЬЮ И ИЗУЧАЙ НАУКИ

У одного египетского эмира было два сына. Один посвятил свою жизнь изучению наук, между тем как другой нажил добро и сделался богат. Первый стал мудрецом, второй — правителем Египта. Однажды богатый брат сказал, с презрением взглянув на учёного: «Я уже стал султаном, а ты всё топчешься на одном месте». «О брат мой, Аллах, да будет свято его имя, всё же на моей стороне, — ответил мудрец, — ибо я стал наследником пророка, в то время как тебе досталось наследство фараона[1]».

О сын мой, из этой притчи ты должен уяснить себе, как важно быть благодарным и что знания, вне всякого сомнения, есть наследие пророка.

[1] Фараон, по поверьям мусульман, — олицетворение алчности и злобы.


30–50%
Углеводы
25–35%
Белки
25–35%
Жиры

*Егерме беренче тәрбия*

## КОРСАГЫҢ ТУЛГАНЧЫ АШАМА, АЗ БЕЛӘН КАНӘГАТЬ БУЛ

Гаҗәм падишаһларыннан бер падишаһ бер оста табибны пәйгамбәр галәйһис-сәлам хезмәтенә йибәрде. Ул табиб ничә еллар гарәб илләрендә торды. Һичбер кеше моңар: «Миңа дәва кыйл», — дип, янына килмәде. Бер көн ул табиб пәйгамбәр галәйһис-сәлам янына килеп шикаять кыйлды. «Фәлән кадәр көннәр монда торамын, һичкем миңа илтифат кыйлган кеше юк», — диде. Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйтте: «Бу халыкның гадәтләре шулдыр ки: ашыйсылары килми торып, һич тәгам ашамаслар, вә тамаклары туймас борын тәгамнан кул тартырлар, ягъни тәмам туйганчы ашамаслар», — диде. Табиб әйтте: «Сыйхәтне булдырмак нәрсә шул лабаса», — дип, йир үпте дә китте.

Имде, әй угыл, бу хикәят тәрбияңне йиткердеме? Имде корсагың тулганча ашама, сыйхәттә булырсән, аз белән канәгать кыйлыр ки, канәгать кирәк. Гыйлем, әлбәттә, пәйгамбәр мирасыдыр.

*Наставление двадцать первое*

## НЕ НАЕДАЙСЯ ДО ОТВАЛА, УМЕЙ ДОВОЛЬСТВОВАТЬСЯ МАЛЫМ

Известно, что один из персидских царей послал однажды лучшего своего лекаря в Аравию, в услужение пророку. Прожил лекарь в Аравии несколько лет, но ни один человек не подошёл к нему и не сказал: «Помоги мне». Тогда пошёл он к пророку и пожаловался: «Я живу здесь столько-то лет, но никто на меня внимания не обращает». Пророк ответил: «Люди здесь не едят, покуда не проголодаются, и отводят руку от еды раньше, чем насытятся, то есть не наедаются до отвала».— «Так вот почему они не знают болезней!» — воскликнул лекарь, поцеловал землю и ушёл.

Думаю, сын мой, ты понял смысл этой притчи. Не наедайся до отвала, неумеренность в еде ведёт к болезням, умей довольствоваться малым.



*Егерме икенче тәрбия*

## ҮЗ НӘФЕСЕН ҖИҢҮЧЕ ГЕНӘ БАҺАДИР БУЛА

Бер адәм гомерендә ничә мәртәбә тәүбә кыйлды, һаман тәүбәсен сындырды. Мәшаихләрдән берәүгә моны шикаять кыйлды: «Тәүбәмне тота алмаймын, гаҗизмән», — диде. Ул мәшаих әйтте: «Мин шуйлә гөман кыйламын ки: син күп ашарга гадәтләнгәнсән, нәфесне җиңмәк бик читен эшдер. Син нәфесне тәрбия кыйлмасаң, ул сине шуйлә зынҗырлар ки, бервакыт сине һәлак кыйлыр», — диде.

Бәс, әй угыл, нәфсең симергән саен, ул сине һәлакәткә тартыр. Дөньяда баһадир шул кешедер ки — нәфесен җиңәр.

*Наставление двадцать второе*

## СИЛЁН ТОТ, КТО УМЕЕТ ПОБЕДИТЬ СВОИ СЛАБОСТИ

Один человек много раз давал клятвы, но всякий раз нарушал их. Он пожаловался старцу: «Я ничего не могу поделать с собой, всё время нарушаю клятвы». Старец сказал: «Я думаю, беда твоя в том, что ты приучил себя к невоздержанности в еде, обуздать плоть — дело нелёгкое. Но если ты и впредь будешь потакать её прихотям, то скоро окажешься её рабом, и тогда она раздавит тебя».

Так что, сын мой, ты погубишь себя, если не научишься подчинять свои желания разуму. Только тот силён, кто умеет победить свои слабости.



*Егерме өченче тәрбия*

## ФӘКЫЙРЬЛЕК ТЕЛӘНЕП ЙӨРҮДӘН ХӘЕРЛЕРӘК

Ишеттем ки, бер фәкыйрь дәрвиш ачлык утына көйгән, бер-берсе өстенә җамаган кием кигән... Дустларыннан берсе әйтте: «Ник утырасән? Ошбу шәһәрдә фәлән кеше бар, мохтаҗларның хаҗәтен үтидер. Әгәр синең дә халеңне белсә, халеңә шәфкать кыйлыр иде», — диде. Ул фәкыйрь әйтте: «Тик тор. Фәкыйрьлектә үлмәк, кешегә хаҗәт белән бармактан хәерлерәкдер», — диде.

*Наставление двадцать третье*

## ЛУЧШЕ БЫТЬ В НИЩЕТЕ, ЧЕМ ПОПРОШАЙНИЧАТЬ

Рассказывают, будто один нищий дервиш, погибая от голода, кутался в старые рубища. «Что же ты сидишь? — спросил его один из товарищей. — Такой-то в этом городе помогает бедным. Ступай к нему, расскажи про свою беду, он подаст тебе что-нибудь». — «Молчи, — ответил дервиш, — лучше умереть в нищете, чем ходить с протянутой рукой».



*Егерме дүртенче тәрбия*

## НӘФЕСЕН ТЫЙМАГАН КЕШЕ АВЫРЛЫКЛАРГА ЧЫДАМЫЙ

Хорасан вилаятендә ике дәрвиш бар иде, бер-беренә юлдаш булып сәфәргә чыктылар. Бере бик зәгыйфь иде, руза тотып ике көнгә бер мәртәбә ифтар кыйла иде. Бере куәтле иде, көн дә өч мәртәбә тәгам ашар иде. Бер шәһәргә керделәр. Ул шәһәрдә боларны, сез шымчыларсыз дип, тотып мәхкәмәгә илттеләр, бер ханәгә яптылар. Ике җомга тәфтиш кыйлганнан соң белделәр ки, гөнаһсыз адәмнәр, имеш. Чыкарып йибәрергә әмер булды. Зинданханәнең ишеген ачып керделәр, күрделәр ки, куәтле дигәне җан тәслим кыйлмыш. Зәгыйфьне карадылар, зәгыйфь дигәне җанын сәламәт асрамыш. Моңар бик гаҗәпкә калдылар. Бер хәким әйтте: «Әгәр моның хилафы вакыйг булган булса, гаҗәп булыр иде. Чөнки ул берсе — күп ашаучы икән, озак ачлыкка тәкать тота алмаган, үлгән. Әмма икенчесе — бер сакланучан адәм, имеш, үзен саклаган вә сабыр кыйлган, сәламәт калган», — диде.

Әй угыл, нәфесен бик тәрбия кыйлган кеше катылыкка чыдамайдыр.

*Наставление двадцать четвёртое*

## КТО НЕ УМЕЕТ НИ В ЧЁМ СЕБЕ ОТКАЗАТЬ, ТОТ ТЯЖЕЛО ПЕРЕНОСИТ ЛИШЕНИЯ

Два дервиша из провинции Хорасан пустились однажды в дальнее странствие. Один был слаб здоровьем, но всё время постился и ел не чаще, чем один раз в два дня. Другой был здоров и ел трижды в день. Вот пришли они в какой-то город. А там приняли их за лазутчиков, схватили и повели к судье, а пока суд да дело, посадили в тюрьму. Через две недели выяснилось, что пришельцы ни в чём не виновны. Было приказано выпустить их. Когда открыли дверь, то увидели, что здоровый из странников умер, а немощный жив. С удивлением смотрели на них люди, а один мудрец сказал: «Было бы странно, случись всё наоборот. Ибо умерший привык много есть и не мог терпеть голод, потому и погиб. Второй же был терпелив, приучил себя подолгу обходиться без пищи, вот и остался жив».

О сын мой, тот тяжело переносит лишения, кто не умеет ни в чём себе отказать.



*Егерме бишенче тәрбия*

## КҮП АШАУ — ИСРАФ

Хәкимнәрдән бер адәм үзенең углын күп ашаудан тыйды. Әйтте: «Әй угыл, күп ашау кешене сырхау итәдер, күп ашама», — диде. Углы әйтте: «Әй ата, ачлык кешене үтерәдер, фәлән кеше ач үлгән диләр, күп ашап үлде дигәнне ишеткәнем юк». Атасы әйтте: «Алай да, углым, үлчәү белән ашамак кирәк. Күп ашау адәмне үтермәсә дә, күп яхшылык та күрмәйдер. Вә исраф буладыр, исраф хәрамдыр», — диде.

Бу кыйссадан сиңа бер тәрбия хасил булсын ки, китап әйткән сүзне бушка хисаплама.

*Наставление двадцать пятое*

## ОБЖОРСТВО — ЭТО РАСТОЧИТЕЛЬСТВО

Один мудрец так поучал сына: «Не ешь много, о сын мой. Избыток пищи навлекает болезни».— «О отец, это голод убивает человека, — возразил ему однажды сын. — Я не раз слышал от людей, что такой-то умер от голода, и ни разу не доводилось мне слышать, чтобы кто-нибудь умер от обильной еды».— «И всё же, сын мой, надо быть умеренным, — ответил мудрец, — если обилие в еде и не убивает, то и хорошего в том мало. Ведь обжорство — расточительство, а это большой грех».

Пусть слова этой притчи будут тебе уроком.



*Егерме алтынчы тәрбия*

## БӘХЕТ БАЙЛЫКТА ТҮГЕЛ

Бер фәкыйрь бервакытны бик мохтаҗ булып калды. Дустларыннан берсе әйтте: «Фәлән кеше бик бай вә нигъмәт иясе адәмдер, әгәр синең мохтаҗ икәнеңне белсә, шаять, шәфкать кыйлыр», — диде.

Бу фәкыйрь әйтте: «Бәлки, шулай булыр иде, әмма мин аны белмәймен», — диде. Ул кеше әйтте: «Әйдә, мин үзем күрсәтәем аны сиңа», — диде.

Бергә бардылар. Бу фәкыйрь, барып йиткәч, ишегалдында берәүне күрде: иреннәре салынган, күңелсез вә хафа утырыр. Бу фәкыйрь бер сүз әйтмәенчә кайтып китте. Баягы кеше сорады: «Ни хәл?» — диде. Фәкыйрь әйтте: «Хәер, үзен күргәч, шәфкатеннән (ваз) кичтем», — диде.

*Наставление двадцать шестое*

## НЕ В БОГАТСТВЕ СЧАСТЬЕ

Один бедняк впал в большую нужду. Друг дал ему совет: «Такой-то человек богат. Если он узнает, что ты бедствуешь, то, наверное, поможет тебе».

«Может, ты и прав, — ответил бедняк, — но я не знаю этого человека». Друг сказал: «Пойдём, я покажу его тебе».

Вот пришли они к дому, во дворе которого увидели невесёлого человека. По-видимому, что-то сильно удручало его. Бедняк повернул назад, так и не заговорив с богачом, ибо понял, что тот достоин ещё большего сострадания.



*Егерме җиденче тәрбия*

## БАЙЛЫК БОЗЫКЛЫККА ЮЛ АЧА

Муса галәйһис-сәлам бер фәкыйрьне күрде: ялангач, киеме юклыктан, комга күмелеп яткан. Фәкыйрь әйтте: «Йә Муса, дога кыйл — Аллаһ Тәгалә миңа байлык бирсен, бу фәкыйрьлегемә чыдарлыгым калмады», — диде. Муса галәйһис-сәлам дога кыйлды. Аз вакыт эчендә Аллаһ Тәгалә теге фәкыйрьне бай итте.

Муса галәйһис-сәлам берникадәр заманнан соң аны янә күрде. Бер урында күп халык җыелган. Муса галәйһис-сәлам сорады: «Ни хәл булды?» — диде. Әйттеләр: «Бу — фәлән кеше, хәмер эчеп исергән, сугышып, бер кешене үтергән. Аны, хөкем итеп, җәза мәйданына алып баралар». Муса галәйһис-сәлам Аллаһ Тәгаләнең хикмәтенә икърар кыйлып: «Баксана, ашыгып дога кыйлдым», — дип үкенде вә тәүбә итте.

Әй угыл, Аллаһ Тәгаләнең илаһи хикмәте бар: берәү бай, берәү фәкыйрь, әмма бай булмак, фәкыйрь булмак адәмнең үз фигыленнән түгелдер. Канәгать булу кирәк.

*Наставление двадцать седьмое*

## БОГАТСТВО ОТКРЫВАЕТ ПУТЬ К РАЗВРАТУ

Пророк Муса повстречал нищего. Совсем нагой, тот лежал по шею зарывшись в песок. «О Муса! — воскликнул он.— Помолись за меня. Пусть Всевышний ниспошлёт мне богатство. Нет уж боле сил моих терпеть нужду». Пророк Муса помолился за нищего, и вскоре Всевышний ниспослал тому богатство.

Спустя некоторое время Мусе вновь довелось встретиться с ним. Завидев взволнованно галдящую толпу, пророк Муса полюбопытствовал: «Что случилось? Почему вы так шумите?» Ему ответили: «Этот человек в пьяном дурмане убил другого человека. И его волокут на лобное место». Муса подивился такому повороту событий. «Как неосмотрительно взывал я к Всевышнему», — сказал он в раскаянии.

О сын мой! Кто будет богат, а кто — беден, знает лишь мудрый Всевышний. Нужно быть благодарным за то, что даровано им.



*Егерме сигезенче тәрбия*

## СИННӘН МОХТАҖРАКЛАРНЫ, ГАРИПЛӘРНЕ КҮРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ

Шәех Сәгъди хикаять кыйлмышдыр ки: «Замананың үзгәрүеннән һәнүз еглаганым вә шикаять кыйлганым юк иде. Мәгәр бервакытны аягыма кияргә юк иде, аякларым ялангач, Күфә мәсҗеденә килдем. Бер аяксызны күрдем, вә Аллаһ Тәгаләгә шөкер вә сәна кыйлдым, вә аягым ялангачлыгына сабыр кыйлдым», — диде.

Имде, әй угыл, бу кыйссадан сиңа бераз тәрбия бирәем.

*Наставление двадцать восьмое*

## ПОДУМАЙ О ТЕХ, КТО НУЖДАЕТСЯ БОЛЬШЕ, ЧЕМ ТЫ

Вот что рассказал мудрый Саади: «Ни разу не жаловался я на превратности жизни. Однажды мне не во что было обуться. Босой пошёл я в мечеть Куфы и увидел там безногого калеку. Тут принялся я горячо благодарить Аллаха, решив терпеливо сносить свою бедность».

Пусть и эта история, о сын мой, послужит тебе уроком.



*Егерме тугызынчы тәрбия*

## БАЛЫКЧЫ ҮЗЕНӘ НАСЫЙП БУЛМАГАН БАЛЫКНЫ ТОТА АЛМЫЙ

Бер бик зәгыйфь балыкчының кармагына бик куәтле олуг балык эләкте. Ул балыкны тартып чыкарырга балыкчының куәте йитмәде. Балык кармакны өзеп качты. Башка балыкчылар, моны күреп, әрләделәр вә шелтә кыйлдылар: «Кармагыңа мондаен кыйммәтле балык эләккән иде, ычкындырдың, һай начар!» — диделәр. Балыкчы әйтте: «Әй егетләр, миңа насыйб булмаган булгач, мин нишли алам? Дәхи балыкның да көне бетмәсә, мин ни кыйлыйм?» — диде.

Балыкчы насыйб булмаган балыкны тоталмай. Балыкның әҗәле йитмәсә, кармакка кералмай.

*Наставление двадцать девятое*

## РЫБАК НЕ СМОЖЕТ ПОЙМАТЬ РЫБУ, НЕ ПРЕДНАЗНАЧЕННУЮ ЕМУ СУДЬБОЙ

В сети немощного сирого рыбака попалась большая рыбина. Но вытащить её из воды ему не хватило сил. Сорвавшись с крючка, рыба уплыла. Рыбаки начали журить бедолагу: «Эх, растяпа, упустил такую рыбину!» Рыбак ответил: «Что же было делать, братцы, коли она не суждена мне? Да и не пришёл ещё последний день этой рыбы».

Не сможет рыбак поймать рыбу, не предназначенную ему судьбой. Рыба, пока не придёт её смертный час, не попадётся на крючок.



*Утызынчы тәрбия*

## БЕРӘҮНЕҢ КАЙГЫСЫН КҮРЕП, БЕРКАЙЧАН ДА СӨЕНӘ КҮРМӘ

Бер сәүдәгәр үзенең сәүдәсендә мең алтын зарар итте вә углына әйтте: «Әй угыл, бу серне кешегә әйтергә кирәкмәс», — диде. Углы әйтте: «Әй ата, фәрман синеңдер. Вә ләкин бу серне яшерүдән безгә ни файда булыр?» Атасы әйтте: «Таки ике кайгы булмасын дип әйтәмен ки, бер кайгы — сәрмаямыз кимүе, икенче кайгы — күршеләремезнең шәматәсе», — диде.

Әй угыл, «шәматә» дигән нәрсә мәзмүм холыкдыр, шәматәдән саклан, ягъни берәүнең кайгысын яки зарарын күреп, яки ишетеп, сәвенмәкне «шәматә» диярләр.

*Наставление тридцатое*

## НИКОГДА НЕ РАДУЙСЯ, УЗНАВ О ГОРЕ ДРУГОГО

Один купец потерпел убыток в тысячу золотых и сказал сыну: «Пусть это будет нашей тайной, не следует рассказывать о том людям».— «Будь по-твоему, отец, но почему мы должны скрывать это?» — спросил сын. «Я не хочу, чтобы мы пострадали дважды: первое горе — то, что мы обеднели на тысячу золотых, второе — злорадство соседей», — ответил купец.

О сын мой, злорадство недостойно человека. Никогда не радуйся, если придётся услышать о разорении или горе другого.



*Утыз беренче тәрбия*

## БЕРНӘРСӘНЕ ТӘМАМ НИГЕЗЕНӘ ТӨШЕНЕП БЕЛМӘСӘҢ, БУ ХАКТА СҮЗ БАШЛАМА

Гакыл иясе вә фазыйләтле бер егет бар иде. Әмма ничә мәртәбә галимнәр вә белем ияләре арасында утырыр, бер сүз сөйләмәс иде. Атасы әйтте: «Әй углым, белгәнеңне ник сөйләмәйсән?» — диде. Углы әйтте: «Куркамын ки, әгәр белгәнемне кешегә белдерсәм, галим икән дип, минем белмәгән нәрсәмне сорарлар да оятлы булырмын», — диде.

Әй угыл, бу хикәяттән сиңа файда шулдыр ки, бернәрсәне тәмам нигезенә төшенеп белмәсәң, телеңә китермә.

*Наставление тридцать первое*

## НИКОГДА НЕ СЛЕДУЕТ ЗАВОДИТЬ РАЗГОВОР, ЕСЛИ НЕ УВЕРЕН, ЧТО ЗНАЕШЬ О ПРЕДМЕТЕ ВСЁ

Жил один умный юноша, обладающий всяческими достоинствами характера. Но сколько ему ни случалось быть среди учёных и мудрых, он всегда скромно помалкивал. «О сын мой, почему ты никогда не рассказываешь того, что знаешь?» — спросил его отец. Юноша ответил: «Боюсь, что люди, приняв меня за учёного, спросят о том, чего я не знаю, и мне будет стыдно».

О сын мой, мудрость этой притчи в том, что никогда не следует заводить разговор, если не уверен, что знаешь о предмете всё.



*Утыз өченче тәрбия*

## БАЙ БАЛАЛАРЫН КЫРЫСРАК ТӘРБИЯЛӘРГӘ КИРӘК

Бер падишаһ үзенең углын остазга гыйлем укымага бирде. Остаз күп иҗтиһад белән падишаһның углына тәгълим бирде, вә яман нәрсәләрдән тыйды, вә кайчак кыйнады. Бу бала, тәкатьсезлегеннән, атасына кайтып шикаять кыйлды, тәнен ачып күрсәтте. Атасы, моңар хафаланып, остазны чакыртты, әйтте: «Әй остаз, гавам балаларын бу кадәр җәфа кыйлмайсан икән, безнең баламызга бу кадәр җәфа вә җәбер күрсәтәсән, ни сәбәпдер?» — диде. Остаз әйтте: «Әй падишаһ, аның өчен ки, гавам балаларына игътибар юкдыр; әмма падишаһ балалары җәфа ни нәрсә, җәбер ни нәрсә икәнен белеп үссеннәр. Таки падишаһ булганнан соң, җәбер вә золым ни икәнен белеп, саклансын. Әгәр падишаһтан вә падишаһ балаларыннан җәбер вә золым башланса, илдән илгә йөртерләр».

Вә шуның кебек олуг кешеләрнең вә байларның балаларын, тәрбия вә тәртип бирүдә гавам балаларыннан артыграк карарга тиеш, ягъни узындырмаенча, тыгызрак тотып тәрбия кыйлырга тиеш, бай дип, ригая кыйлырга ярамый.

*Наставление тридцать третье*

## ПРИ ОБУЧЕНИИ И ВОСПИТАНИИ С БОГАТЫХ СЛЕДУЕТ ВЗЫСКИВАТЬ СТРОЖЕ

Один падишах отдал сына наставнику. Тот с большим усердием принялся за обучение сына падишаха, строго взыскивал с мальчика за всё дурное и даже бил иногда. Мальчик не выдержал притеснений учителя и прибежал к отцу с жалобами, показал ему своё тело. Отца огорчило это, он приказал позвать наставника и спросил: «Почему ты так жесток и безжалостен с нашим сыном, о учитель, тогда как с детьми черни обходишься гораздо мягче?»

«О падишах, на дурные дела детей простолюдинов никто не обращает внимания, но сын падишаха должен знать, что такое зло. И когда он станет падишахом, пусть остерегается жестокости и несправедливости. Весть о злых делах владык летит из одной страны в другую и плодит последователей».

Вот почему при обучении и воспитании с отпрысков людей богатых и знатных следует взыскивать строже, чем с детей простолюдинов, то есть не давать им воли, не позволять лишнего и не баловать вниманием лишь потому, что они из богатых и знатных семей.


2 + 2 = 4
4 × 4 = 16
√(16)
16 1/4  16 4/1

*Утыз дүртенче тәрбия*

## ЯШЬ ЧАКТА АЛГАН ГЫЙЛЕМ ТАШКА ЧОКЫП ЯСАЛГАН БИЗӘК КЕБЕК

Әй угыл, балаларга тәгълим бирсәң, кечерәк вакытта бик иҗтиһад кыйл, «Әл-гыйльме фис-сәгъри кә нәкаши фил-хәҗәри»[1] мазмунынча, чыбыкны нечкәрәк чагында бөгү уңайракка киләдер. Кечерәк вакытта күп фәннәргә төшендермәк кирәк, математиканы аз-аз белдермәк тиеш. Әмма бу балаларга сабак укыту хосусында сиңа яхшырак тәрбия бирәем.

*Наставление тридцать четвёртое*

## ЗНАНИЯ, ПОЛУЧЕННЫЕ В ДЕТСТВЕ, ПОДОБНЫ ОРНАМЕНТУ, ВЫБИТОМУ НА КАМНЕ

О сын мой, когда придётся тебе воспитывать детей, будь особенно старателен, пока они малы. Знания, полученные в детстве, подобны орнаменту, выбитому на камне. Прут легче гнётся, покуда тонок. В нежном возрасте следует внушать понятия о многих науках и давать кое-какие знания даже по математике. Вопросы образования детей требуют глубокого вдумчивого изучения.

[1] «Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәккә охшаш» мәгънәсендә.



*Утыз бишенче тәрбия*

## ТӘРБИЯ БЕРДЕР, ЛӘКИН СӘЛӘТЛЕЛЕК ТӨРЛЕ

Бер падишаһ углын бер остазга бирде, әйтте: «Әй остаз, бу бала синеңдер, үз низамыңча яхшы тәгълим биргәйсән», — диде. Бәс, остаз бу падишаһ баласына башка балалар белән бер дәрәҗәдә белем бирде. Ләкин падишаһ баласы гавам балалары йиткән дәрәҗәгә йитмәде. Бәс, падишаһ шелтәләмәкче булды. Остаз әйтте: «Әй падишаһ, тәрбия бердер, ләкин сәләтлелек башкадыр», — диде.

Бәс, әй угыл, гавам балалары күбрәк бай балаларыннан өлгеррәк вә зирәгрәккә киләдер. Мин сиңа шуның өчен әйтәмен: бай балаларына артыграк иҗтиһад сарыф кыйлмак кирәк, алар бик иркә булалар.

*Наставление тридцать пятое*

## ОБУЧЕНИЕ ОДИНАКОВО, ДА СПОСОБНОСТИ РАЗНЫЕ

Один падишах передал сына наставнику, говоря: «О учитель, воспитай этого ребенка, как своего собственного сына, по своей системе, дай ему хорошие знания». Наставник принялся с усердием обучать сына падишаха вместе с другими отроками. Однако сын падишаха учился хуже сыновей простолюдинов. Падишах упрекнул этим наставника. Но тот отвечал: «О падишах, обучение одинаково, да способности разные».

Учти, мой сын, что дети простолюдинов бывают порой куда проворней и смышлёней байских сынков. Вот почему я ещё раз повторяю, что обучение байских детей требует гораздо больше стараний, ибо бывают они чересчур избалованы.



*Утыз алтынчы тәрбия*

## КЕМ УЛЫ БУЛУЫҢ ТҮГЕЛ, ГАМӘЛЕҢ МӨҺИМ

Бер гарәп үзенең углына әйтте: «Бак, угыл, кыямәт көнендә синнән: «Син кем углы?» — дип сорамаслар, бәлки: «Ни гамәл китердең?» — дип сорарлар», — диде.

*Наставление тридцать шестое*

## НЕ ВАЖНО, ЧЕЙ ТЫ СЫН, ВАЖНО, ЧТО ПОЛЕЗНОГО ТЫ СДЕЛАЛ

Один араб так поучал сына: «В день страшного суда тебя не спросят, чей ты сын, а спросят, что полезного ты сделал».



*Утыз җиденче тәрбия*

## БАЛАҢ БАР ИКӘН, АҢА ЯХШЫ ТӘРБИЯ БИРЕРГӘ ДӘ КИРӘК

Шәех Сәгъди риваять кыйлмышдыр ки, бер фәкыйрь адәм бар иде, гомерендә бала күрмәде, Аллаһ Тәгаләдән сорады: «Әгәр углым булса, ошбу өстемдәге хиркамнан башка милкемдә нәрсә юкдыр, аны сатып фәкыйрь-фокарага өләшер идем», — дип нәзер кыйлды. Бәс, Аллаһ Тәгалә аңа бер угыл рузи кыйлды. Бик шатланып, әйткән нәзерне тотты, фәкыйрьләргә хәер кыйлды. Берничә елдан, янә Шам сәфәреннән кайтканда, юлым шул шәһәргә тугры килеп, ул кешене сораштым. Әйттеләр, зиндандадыр. «Ни сәбәпле зинданга төште?» — дип сорадым. «Углы бер вакытны хәмер эчеп сугышып, бер адәмне үтергән иде, һәм шәһәрдән качкан иде. Углын тапмагач, углы урынына атасын зинданга салдылар».

Әй угыл, ошбу заманамызда да моңар охшашлы вакыйгалар бардыр ки, ниндәен байлар бар, балалары яшь вә кечкенә заманда, кырык-илле мең, йөз мең белән сәүдә кыйлгучылар. Балалары үсеп йиткәч, фәкыйрь вә мохтаҗлыкка калалар. Ул нидәндер? Әлбәттә, кечкенә вакытта балаларын яхшы тәрбия кыйла белмәгәнлектәндер.

*Наставление тридцать седьмое*

## НЕДОСТАТОЧНО ИМЕТЬ РЕБЕНКА, ЕГО НУЖНО И ПРАВИЛЬНО ВОСПИТАТЬ

Мудрый Саади рассказывал про одного бедного человека, у которого не было детей. Тот обратился к Аллаху с мольбой дать ему сына. «Если бы у меня родился сын, — говорил он, — я продал бы всё, кроме последней рубахи на себе, а деньги раздал бы нищим». Таков был его обет. И Аллах подарил ему сына. На радостях человек этот поступил, как обещал: всем бедным оказал благодеяние и милость. Через несколько лет, возвращаясь из Дамаска, Саади снова побывал в том городе и расспросил людей об этом человеке. Ему сказали, что несчастный попал в тюрьму. «За что же его наказали?» — спросил Саади. Ему отвечали: «Из-за сына. Однажды он напился вина, убил в драке человека и сбежал из города. Вместо него посадили отца».

О сын мой, такие случаи не редкость и в наши дни. Известны богачи, в делах ворочавшие огромными суммами в сорок, пятьдесят, сто тысяч. А дети их, выросши, остаются ни с чем. Отчего это? А всё оттого, что они не умели дать своим детям должного воспитания.



*Утыз сигезенче тәрбия*

## НӘФЕС ДОШМАННАН ЯМАНРАК

Бер олуг галим әйтте: «Һәрбер дошманга, ихсан кыйлсаң (яхшылык итсәң), дуст тотадыр. Мәгәр нәфес ки, таләбен никадәр бирсәң, шулкадәр күбрәк телидер», — диде.

*Наставление тридцать восьмое*

## СТРАСТИ СТРАШНЕЕ ВРАГА

Один почтенный мудрец сказал: «Чем больше хорошего делаешь врагу, тем добрее становится он к тебе. Страсти же наоборот. Чем больше их удовлетворяешь, тем ненасытнее становишься».



*Утыз тугызынчы тәрбия*

## ЯВЫЗ БӘХЕТТӘН САКЛАН

Хикмәт: мал дигән нәрсә «гомерне тынычлык белән кичермәк өчендер»; түгелдер ки — фәкать мал җыймак өчен. Бер гакыл иясеннән сорадылар. «Изге бәхетле кемдер, дәхи явыз бәхетле кемдер?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Изге бәхетлелекнең галәмәте шулдыр ки, дөньяда пәрһизкяр булыр, ахирәтне онытмас, гыйбадәтчән булыр, вә Коръән укучан булыр, аз сүзле булыр, биш вакыт намазын вакытында әда кыйлыр, хәрамнан сакланыр, изгеләргә мәхәббәт итәр, кече күңелле булыр, җумард булыр, шәфкатьле булыр. Әмма явыз бәхетле шулдыр ки, мал җыярга хирыс булыр, нәфесенә иярер, күп сөйләшер, намазга ялкау булыр, явызларны яратыр, явыз холыклы булыр, хәйләкәр булыр, шәфкатьсез булыр, саран булыр, үлемне онытыр.

Әй угыл, бу урында сиңа яхшы бер тәрбия бардыр ки, изге бәхетле бул, явыз бәхеттән саклан, монда сиңа изге бәхет галәмәтләрен санап китерүдән максуд, сине изге бәхетле кыйлмакдыр.

*Наставление тридцать девятое*

## ОСТЕРЕГАЙСЯ ЗЛОГО СЧАСТЬЯ

Деньги нужны для того, чтобы спокойно прожить жизнь, а не для того, чтобы копить их. Когда одного мудреца спросили: «Что есть счастье доброе и счастье злое?», он ответил: «Доброе счастье бывает воздержанным, всегда помнит друзей, оно благочестиво, следует заветам Корана, малословно, вовремя совершает пятикратный намаз, безгрешно, поклоняется святым, учтиво, щедро, милосердно. А злое счастье? Это стяжательство, невоздержанность, болтливость, лень в чтении намаза, жестокость, лукавство, бессердечие, жадность; оно забывает, что жизнь не вечна».

О сын мой, это хороший урок для тебя: стремись к доброму счастью и берегись злого; цель перечисления признаков доброго счастья была в том, чтобы сделать тебя по-настоящему счастливым.



*Кырыгынчы тәрбия*

## БЕРӘҮ СИҢА ИЗГЕ НӘСИХӘТ КЫЛСА, УЛ ӨЙРӘТКӘНЧӘ ГАМӘЛ КЫЛ

Муса галәйһис-сәлам Карунга мондый нәсихәт бирде: «Аллаһ Тәгалә сиңа ихсан кыйлды. Инде син дә ихсан һәм изгелек кыйл», — диде. Карун Мусаның сүзен тыңламады. Малы-мөлкәте белән аны йир йотты.

Инде, әй угыл, берәү сиңа изге нәсихәт кыйлса, җаның-күңелең белән аны тыңла — ул өйрәткәнчә гамәл кыйл.

*Наставление сороковое*

## ЕСЛИ КТО-ТО ДАСТ ТЕБЕ ДОБРЫЙ СОВЕТ, ПОСТАРАЙСЯ ПРЕТВОРИТЬ ЕГО В ЖИЗНЬ

Пророк Муса наставлял Каруна: «Всевышний одарил тебя — сделал богатым. И ты окажи ему благодеяние». Но не послушал Карун Мусу, и со всем добром поглотила его преисподняя. О сын мой! Если кто-то даст тебе добрый совет, постарайся претворить его в жизнь.



*Кырык беренче тәрбия*

## ТУПЛАГАН ГЫЙЛЕМЕҢ БЕЛӘН ГАМӘЛ КЫЛ

Әй угыл, ике төрле таифә бардыр ки, файдасызга вә мәгънәсезгә зәхмәт чигәрләр. Бере шулдыр ки, акча вә мал җыяр, үзе файдаланмас. Янә бере шул галимдер ки, гыйлем үгрәнде, гамәл кыйлмады. Бу ике таифә җөмләсеннән була күрмә, әй угыл.

*Наставление сорок первое*

## ИСПОЛЬЗУЙ НАКОПЛЕННЫЕ ЗНАНИЯ ДЛЯ ПОЛЕЗНЫХ ДЕЛ

О сын мой, есть две группы людей, жизнь которых бессмысленна и бесполезна. Одни всю жизнь копят добро и не пользуются им. Другие всю жизнь копят знания, но не используют их для дела. Бойся оказаться в их числе.



*Кырык икенче тәрбия*

## ДУСТЫҢ БЕРВАКЫТ — ДОШМАНГА, Ә ДОШМАНЫҢ ДУСТЫҢА ӘЙЛӘНЕРГӘ МӨМКИН

Һәрбер сереңне дустыңа әйтмә, чөнки кайдан беләсең, бервакытны дошман булып китәр. Дошманыңа, кулыңнан килсә, зарар итмә, бәлки, бервакытны үзеңә дуст булыр. Дустыңның дустына да ышаныч юк, аң бул. Әмма ике дошман арасында сүз сөйләсәң, белеп сөйлә: әгәр дустлансалар, үзеңә оят килмәсен.

*Наставление сорок второе*

## ДРУГ ОДНАЖДЫ МОЖЕТ СТАТЬ ВРАГОМ, А ВРАГ — ДРУГОМ

Не рассказывай самые сокровенные свои тайны даже другу, ведь однажды он может стать твоим врагом. Не причиняй зла врагу, ибо он может стать тебе другом. Помни: опасно доверяться другу твоего друга. Ну, а случится быть между двух врагов, будь осторожен и не говори лишнего, ведь они помирятся, краснеть же придётся тебе.



*Кырык өченче тәрбия*

## ХӘТТА ДИВАР ЯНЫНДА СӨЙЛӘСӘҢ ДӘ, АКЫЛ БЕЛӘН СӨЙЛӘШ, ДИВАР АРТЫНДА КОЛАК БУЛМАСЫН

Дустың белән сөйләшкәндә акрын сөйләш, сөйләшкән сүзең дошманыңа ирешмәсен. Хәтта бер дивар янында сөйләсәң дә, гакыл белән сөйләш, таки дивар артында колак булмасын. Әмма дошманның нәсихәтен кабул итмәк хатадыр. Ләкин ишетмәк җаиз, чөнки гыйбрәт алып гамәл кыйлгайсән.

*Наставление сорок третье*

## ОСТЕРЕГАТЬСЯ СЛЕДУЕТ ДАЖЕ СТЕН, ИБО И У НИХ БЫВАЮТ УШИ

С другом следует говорить шёпотом, чтобы недруг не мог подслушать. Остерегаться следует даже стен, ибо и у них бывают уши. Следовать совету недруга — ошибка, но выслушать его надо: хотя бы для того, чтобы поступить наоборот.



*Кырык дүртенче тәрбия*

## КУӘТЕҢ БАРЫНДА ИЗГЕЛЕК КЫЛ

Әй угыл, куәте барында изге гамәл кыйлмаган кеше зәгыйфь вакытында катылык күрер.

*Наставление сорок четвёртое*

## ТВОРИ ДОБРО, ПОКА ЕСТЬ СИЛЫ

О сын мой, кто не творил добра, когда был силён, в слабости познаёт тяготы.



*Кырык бишенче тәрбия*

# ҖИДЕ ТӨРЛЕ КЕШЕДӘН КИҢӘШ АЛМА

Әй угыл, йиде төрле кешегә киңәш итмә. Әүвәл, надан кешегә киңәш итмә, чөнки надан кеше, үзенең наданлыгына булышып, сине азгынлык юлына салыр. Икенче, дошманыңа киңәш итмә, чөнки дошман кеше сине һәлакәткә тартыр. Өченче, хасидкә вә көнче кешегә киңәш итмә, чөнки көнче кеше синең нигъмәтеңә зыян килүен теләр. Дүртенче, икейөзле кешегә киңәш итмә. Чөнки ул кеше һәркайчан адәмнең ризалыгын гына карап торыр. Бишенче, куркак кешегә киңәш итмә, чөнки куркак кеше сиңа һичбер мәслихәт бирергә җөрьәт кыйлмас. Алтынчы, саран кешегә киңәш итмә, чөнки саран кеше мал җыярга хирысдыр, анда дөрес киңәш юкдыр. Йиденче, һәвәскә ияргән кешегә киңәш итмә, чөнки нәфес арзусына ияргән кеше нәфесенә каршылык кыйла алмас.

*Наставление сорок пятое*

# ИЗБЕГАЙ СОВЕТОВ СЕМИ ЧЕЛОВЕК

Избегай советов семи человек, о сын мой. Во-первых, остерегайся невежды, ибо он тёмен и может толкнуть тебя на ложный путь. Во-вторых, берегись совета врага: он может погубить тебя. В-третьих, страшись совета завистника и ревнивца: этот разорит тебя. В-четвёртых, не советуйся с лицемером, ибо лицемер заранее согласится с тобой. В-пятых, не слушай советов труса: он не отважится сказать правду. В-шестых, не верь скряге: у него на уме одно стяжательство и нет верных мыслей. И наконец, не вздумай советоваться с одержимым, ибо он не в силах справиться даже со своей страстью.



*Кырык алтынчы тәрбия*

## ИСЕМЕҢНЕ МАКТАП ТЕЛГӘ АЛСЫННАР

Халыкка икмәк-тоз күрсәтмәгән кешенең үлгәч тә исемен телгә алмаслар. Тереклеге белән сөендермәгән кешенең үлеменә дә бик кайгырмаслар.

*Наставление сорок шестое*

## ПУСТЬ ВСПОМИНАЮТ ТВОЁ ИМЯ С БЛАГОДАРНОСТЬЮ

Того, кто скупился на хлеб-соль, не вспомнят и после кончины. Кто не радовал своей жизнью, тот не огорчит и смертью.



*Кырык сигезенче тәрбия*

## САУЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛ

Әй угыл, үзеңнең сихәтеңә вә үткән көннең сәламәтлегенә горурланма вә алданма. Чөнки гомереңнең вакыты аздыр, даимән сихәттә булмакың бар. Бәс, сихәтнең кадерен бел, үзеңне хайван дәрәҗәсеннән чыкар. Ләкин сихәтлекне саклау шартлары күпдер.

*Наставление сорок восьмое*

## БЕРЕГИ И ЦЕНИ СВОЁ ЗДОРОВЬЕ

Не кичись здоровьем и не обманывай себя благополучием прежних дней, о сын мой. Всегда здоровым быть нельзя. Поэтому береги себя и не доводи до скотства. Знай, что здоровье сохранит лишь тот, кто следует многим заповедям.



*Кырык тугызынчы тәрбия*

## НИ ЧӘЧСӘҢ, ШУНЫ УРЫРСЫҢ

Әй угыл, сачкәнеңне урырсың, кыйлганыңны күрерсең, ягъни изге эш кыйлсаң, изге җәза алырсың вә явыз эш кыйлсаң, михнәткә вә газапка лаек булырсың.

*Наставление сорок девятое*

## ЧТО ПОСЕЕШЬ, ТО И ПОЖНЁШЬ

Что посеешь, то и пожнёшь, о сын мой. Это значит, что за добро тебе воздастся добром, а за зло ты заслужишь лишь страдания и муки.



*Илленче тәрбия*

## САРАН КЕШЕ ҮЗ МАЛЫНЫҢ КАРАВЫЛЧЫСЫ ГЫНА УЛ

Әй угыл, саран кеше фәкать үз малының каравылчысыдыр вә варисларының хәзинәчеседер, ягъни үзенең малына бары каравыл тора вә варисларына тапшырмак өчен бары вакытын көтәдер. Бу хикмәтләрнең гарәпчәсе — «Фәвакиһелҗөләса»дә[1].

*Наставление пятидесятое*

## СКУПЕЦ — ВСЕГО ЛИШЬ СТРАЖ СОБСТВЕННОГО ДОБРА

Скупец — всего лишь страж собственного добра и казначей своих наследников. Его жизнь — ожидание часа, когда можно будет всё передать им. Мудрые изречения, подобные этому, ты можешь прочитать на арабском языке в книге «Плоды собеседований»[1].

---

[1] Каюм Насыйриның 1884 елда чыккан шундый исемдәге китабы бар. Речь идёт о книге Каюма Насыри «Плоды собеседований по литературе», 1884 год.



*Илле беренче тәрбия*

## ЯМАН ХОЛЫКЛЫ КЕШЕГӘ ГАМӘЛЕҢ БЕЛӘН НӘСИХӘТ КЫЛ

Әй угыл, әхлакы яман кешегә вә явыз холыклы кемсәнәгә күркәм фигылең вә изге холыкларыңны күрсәтмәк белән вәгазь вә нәсихәт кыйл, телең белән нәсихәт кыйлганчы, фигылең белән нәсихәт кыйл димәкдер. Шаять ки, бу сүзне бәян кыйлмасам да, фәһем итсәң кирәк.

*Наставление пятьдесят первое*

## ЧЕЛОВЕКА С ДУРНЫМ НРАВОМ СЛЕДУЕТ ВОСПИТЫВАТЬ ДОБРЫМИ ДЕЛАМИ

О сын мой, человека с дурным и злым нравом следует воспитывать не словами, а добрыми делами. Ты, конечно, и сам это хорошо понимаешь.



*Илле икенче тәрбия*

## ЯХШЫЛЫКНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛМӘГӘН КЕШЕДӘН ЕРАК ЙӨР

Әй угыл, яхшылыкның кадерен белмәгән кешедән ерак булган яхшы. Берәүгә бер яхшылыгың тисә, искә төшереп йөрмә, берәүдән яхшылык күрсәң — фаш кыйл, онытма.

*Наставление пятьдесят второе*

## СТОРОНИСЬ ЛЮДЕЙ НЕБЛАГОДАРНЫХ

О сын мой, сторонись людей неблагодарных. Сделав добро, никогда не хвастайся этим, но если добро сделали тебе, не забывай рассказывать об этом повсюду.



*Илле өченче тәрбия*

## ӘҖӘЛ КӨТМӘГӘНДӘ КИЛЕРГӘ МӨМКИН

Әй угыл, һәрникадәр җисмеңдә сихәт вә затыңда яшьлек вә егетлек булса да, тәүбәсез вә васыятьсез ятып йоклама. Адәмнең әҗәле күз белән каш арасындадыр.

*Наставление пятьдесят третье*

## СМЕРТЬ МОЖЕТ НАСТИЧЬ В ЛЮБОЙ МИГ

О сын мой, как бы ни был ты крепок телом, молод и бодр душой, не ложись спать, не покаявшись и не оставив завещания. Ведь смерть может настичь тебя в любой миг.



*Илле дүртенче тәрбия*

## САФ КҮҢЕЛЛЕ, КҮРКӘМ ФИГЫЛЬЛЕ КЕШЕ ХӨРМӘТ-ИХТИРАМГА ЛАЕК

Әй угыл, күршеләрен игътибарсыз вә ихтирамсыз тоткан кеше газиз вә хөрмәтле була алмас. Вә карендәшләрен мәхрүм куйган кеше — малының рәхәтен табалмас. Саф күңелле вә күркәм фигыльле булган кешене олылау вә ихтирам кыйлмак зарурдыр.

*Наставление пятьдесят четвёртое*

## ПРИВЕТЛИВЫЙ И ДОБРЫЙ ЧЕЛОВЕК ЗАСЛУЖИВАЕТ УВАЖЕНИЯ И ПОЧЕСТЕЙ

О сын мой, тот, кто позорит и унижает соседей, недостоин уважения. Тот, кто обделяет родных, никогда не познает радости от своего богатства. Только приветливый и добрый человек заслуживает уважения и почестей.



*Илле бишенче тәрбия*

## ГАФУ ИТӘ БЕЛҮ — ИҢ КҮРКӘМ СЫЙФАТ

Әй угыл, бер кеше сине явыз холкы белән рәнҗетсә, эчкерсезлегең белән аңа вәгазь кыйл, ягъни аннан үч алаем дип мәшәкать чикмә. Егетлек вә инсаниятнең тәмамыннандыр ки, һәрни җәһәттән булса да, гайреләрдә булган хакыңны оныткайсән. Гайренең синдә булган хакын хәтереңдә тоткайсән, моны егетлек диярләр. Үч алырга вә җәза бирергә кадәр була торып гафу кыйлмак — барча изге холыкларның күркәмрәгедер.

*Наставление пятьдесят пятое*

## УМЕНИЕ ПРОЩАТЬ — САМОЕ ПРЕКРАСНОЕ ИЗ ЧЕЛОВЕЧЕСКИХ ДОСТОИНСТВ

О сын мой, если кто-нибудь оскорбит тебя грубостью, не вздумай ответить тем же, лучше мягко пожури обидчика.

Твои великодушие и человечность лишь тогда проявятся до конца, если ты найдёшь в себе силы забыть, чем обязаны тебе люди. Сам, однако, вечно помни их доброту. Это и есть истинное мужество.

Умение прощать даже тогда, когда можешь наказать местью, — вот самое прекрасное из человеческих достоинств.



*Илле алтынчы тәрбия*

## МОХТАҖГА ҮЗЕ СОРАГАНЧЫ ЯРДӘМ КҮРСӘТ

Берәүнең мохтаҗ икәнен беләсән икән, вә һәм миннән хаҗәт теләр, дигән гөманың бар икән, үзе сорамас борын, тизрәк бирә күр.

*Наставление пятьдесят шестое*

## ПЕРВЫМ ПРОТЯНИ РУКУ ПОМОЩИ НУЖДАЮЩЕМУСЯ

Если ты знаешь, что некто впал в нужду, и догадываешься, что он рассчитывает на твою поддержку, не жди, пока он сам попросит тебя об этом, первый протяни руку помощи.



*Илле җиденче тәрбия*

## ИГЕЛЕГЕҢНЕ ИСКӘ ТӨШЕРМӘ

Әй угыл, берәүгә иткән игелегең вә ярдәмеңне вә аңар иткән яхшылыкыңны әйтеп: «Мин сиңа фәлән яхшылыклар кыйлдым», — дип исенә төшереп йөрсәң, адәм тарафыннан рәхмәт вә Аллаһ Тәгалә тарафыннан савап өмид итмә. Син исенә төшермәсәң дә, ул кеше үзе дә белер, вә Аллаһ Тәгалә дә синең кыйлган изгелекләреңне белер.

*Наставление пятьдесят седьмое*

## НЕ НАПОМИНАЙ О СВОЁМ БЛАГОМ ДЕЯНИИ

О сын мой, если ты будешь хвастаться перед человеком своей добротой, приговаривая: «Я сделал для тебя то-то и то-то», — не жди благодарности от людей и милости от Аллаха. Человек этот и без твоих напоминаний знает, чем обязан тебе. Также и Всевышний ведает обо всех твоих благих деяниях.



*Илле сигезенче тәрбия*

## ТАР ХОЛЫКЛЫ КЕШЕНЕҢ РИЗЫГЫ ДА ТАР

Әй угыл, тар холыклы кешенең ризкы да тар була, имеш. Киң холыклы вә сабырлы булу тиеш. Тугры сүзле кешенең матурлыгы артык булыр, ягъни сүзендә вә фигылендә тугры кешегә халык мәхәббәт итәдер. Нитәкки матур кешене халык: «Һай, матур кеше икән», — дип мәхәббәт итәдер.

*Наставление пятьдесят восьмое*

## У НЕПРИВЕТЛИВОГО ХОЗЯИНА И УГОЩЕНИЕ ПОПЕРЁК ГОРЛА

О сын мой, как говорится, у неприветливого хозяина и угощение поперёк горла. Надо быть радушным и терпеливым. Искренность также притягивает к себе сердца людей. Как нельзя не восхититься красотой, так нельзя не полюбить открытого, приветливого человека.



*Илле тугызынчы тәрбия*

## ХӘЛӘЛ КӘСЕПТӘН КИЛГӘН МАЛНЫ ХӘРАМГА САРЫФ КЫЛЫРГА ЯРАМЫЙ

Хәерле мал шулдыр ки: хәләлдән килер; изге юлга сарыф кыйлыныр. Хәерсез мал шулдыр ки: хәрамнан килеп, начарлык һәм әшәкелекләр юлына сарыф кыйлыныр. Моннан нәтиҗә шулдыр: әй угыл, изге юлда хәләл кәсептән хасыйл булган малны хәрамга сарыф кыйлынмасдыр. Вә аны хәрамга сарыф кыйлырга Аллаһ Тәгалә ирек бирмәйдер. Хәләлдән килгән акча асла хәрамга китмәс. Һәм ул мал иясендә карар кыйлыр, үлгәнче ул кеше дәүләттән чыкмас, байлыгыннан аерылмас. Вә хәрамнан килгән мал исә иясенә йокмайдыр. Ул хәрамнан килгән мал янә хәрамга китеп бетәдер; китә башласа, иясе дә аны туктата алмайдыр, тиз заман эчендә мохтаҗ булып каладыр.

*Наставление пятьдесят девятое*

## НЕЛЬЗЯ ОСКВЕРНЯТЬ БОГАТСТВО, НАЖИТОЕ ЧЕСТНЫМ ТРУДОМ

Честно заработанное добро и тратится на добрые дела. Богатство, нажитое нечестным путём, тратится на недобрые дела. О сын мой! Нельзя осквернять богатство, нажитое честным трудом, направив его на дурные дела. Да и сам Всевышний воспрепятствует этому. Честно заработанные деньги не пойдут прахом. Владелец честно нажитого до смерти будет довольствоваться плодами своего труда.

Богатства, доставшиеся нечестно, надолго в руках не задержатся, уйдут таким же нечестным путём. И владелец никак не сможет воспрепятствовать этому и проведёт в нужде оставшиеся дни свои.



*Алтмышынчы тәрбия*

## СИҢА ИЗГЕЛЕК КЫЛГАН КЕШЕГӘ ЯМАНЛЫК ЭШЛӘМӘ

Әй угыл, белеп тор ки, сиңа изгелек кыйлган кешегә яманлык кыйлма, вә сиңа нигъмәт биргән кешене хурлама вә кимсетүле караш белән карама, залимлыгы күп булган кеше тиз һәлак буладыр, вә һәм дошманнары күп буладыр. Залимлыктан зиядә сакланмак кирәк.

*Наставление шестидесятое*

## НЕЛЬЗЯ НА ДОБРО ОТВЕЧАТЬ ЗЛОМ

О сын мой, помни, что нельзя на добро отвечать злом. Никогда не презирай того, кто поделился с тобой хлебом. Жестокий человек наживает много врагов и рано погибает. Бойся жестокости.



*Алтмыш беренче тәрбия*

## ЗАЛИМНӘРГӘ ЯРДӘМ ИТҮЧЕ — ЗАЛИМНӘРНЕҢ БЕРСЕДЕР

Залимнәргә өстенлек вә ярдәм биргүче кеше — залимнәрнең берседер вә адәмиләрнең явызрагыдыр. Әмма, әй угыл, залимлек дигән нәрсә акча вә гайре нәрсә хакында гына түгел, бәлки сүздә вә фигыльдә һәм залимлек буладыр.

*Наставление шестьдесят первое*

## ТОТ, КТО ПОДДЕРЖИВАЕТ ТИРАНА ЯВЛЯЕТСЯ ТАКИМ ЖЕ ТИРАНОМ

Деспота поддержит и поможет ему или такой же деспот, или самый злобный из людей. Но, сын мой, деспотизм проявляется не только в спорах за золото; в словах, житейских делах и поступках он тоже возможен.



*Алтмыш икенче тәрбия*

## АКЫЛЛЫ БУЛЫП КЫЛАНЫП, УРЫНСЫЗ ҖИРДӘ НӘСИХӘТ КЫЛЫРГА МАТАШМА

Халык арасында берәүне вәгазь вә нәсихәт кыйлмак — аның башына сукмак кебекдер. Һичшиксез, ул кеше сиңа дошман булыр. Ул синең нәсихәтеңне тоту кая, хәтта синең һәлакеңә юл эзләр. Халыкка сыпыйлыгыңны (суфыйлыгыңны) күрсәткән булып, булыр-булмас йирдә нәсихәт кыйлган булып маташма.

*Наставление шестьдесят второе*

## НЕ УМНИЧАЙ И НЕ ЛЕЗЬ С ПОУЧЕНИЯМИ ТАМ, ГДЕ ЭТО НЕУМЕСТНО

Сделать иному при всех замечание — это всё равно что ударить его по голове. Он ведь не послушается твоего совета, а лишь затаит на тебя злобу. Лучше уж не умничай и не лезь с поучениями там, где это неуместно.



*Алтмыш өченче тәрбия*

## АЛЫШ-БИРЕШ — БАШКА, КАРДӘШЛЕК — БАШКА

Әй угыл, карендәшләрчә аралаш, ятларча мөгамәлә кыйл. Ягъни алышта-бирештә: «Бу — карендәш кеше», — дип өстенлек кыйлма. Вә дәхи алышта-бирештә: «Мин карендәш кеше ләбаса, азрак өстенлек кыйл», — димә. Чөнки мал — башка, карендәшлек — башка, бу хосуста яклашу ачу тотуга вә дошманлыкка сәбәпче буладыр. Әгәр яклау кыйлышмак лязем булганда да, сәүдәләшү тәмам булгач кыйлмак тиеш.

*Наставление шестьдесят третье*

## РОДНЯ РОДНЁЙ, А ДЕЛА ДЕЛАМИ

В дружбе с близкими будь братом, но в делах все для тебя должны быть равны. При купле-продаже не делай для родственников исключения, говоря: «Он мне родня». И никогда не проси: «Я — тебе родня, сбавь немного цену». Потому что родня родней, а дела делами. В деловых вопросах напоминание о дружбе и родстве вызывает обиду, озлобление. Если хочешь оказать ближнему любезность, лучше сделай это после того, как будет окончен торг.



*Алтмыш дүртенче тәрбия*

## ЯХШЫ ҺӘМ ЙОМШАК СҮЗГӘ КЕШЕНЕҢ КҮҢЕЛЕ ЭРЕП КИТӘ

Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачыракдыр вә яманракдыр, ягъни телдән әйтелгән ачы вә кабахәт сүзләрнең адәмгә әсәре тәнеңне пычкы белән кискәннән дә ачыракдыр. Әй угыл, һичбер кешегә телең белән җәрәхәт салма, ни яман сүз әйтмә. Адәмнең җанына тия торган сүз әйтмә. Әмма бер сүзне син кулай хисаплап әйтерсән дә, кешенең күңеленә бик каты тияр. Әй угыл, каты сүзле булма. Изге холык белән вә йомшаклык белән татлы сүзләр сөйләшмәк — ризыкның ачкычыдыр, димешләр. Яхшы вә йомшак сүзгә адәмнең күңеле эреп китәдер. Кешегә ашыгып сүз әйтсәң вә ашыгып җавап бирсәң, һичбер хата сүз садир булмаенча булмас.

*Наставление шестьдесят четвёртое*

## НАВСТРЕЧУ ПРИВЕТЛИВЫМ СЛОВАМ РАСКРЫВАЮТСЯ СЕРДЦА ЛЮДЕЙ

Злой язык опасней стали. Слово, слетевшее с языка, ранит порой так жестоко, что легче вынести боль, причиняемую при отсечении частей тела. О сын мой, никогда не огорчай людей неосторожным словом. Беспощадное слово способно пронзить сердце. Иной раз может показаться, что речи твои обычны, а кому-то они причинят обиду.

О сын мой, не будь дерзок и груб на язык. Ведь недаром говорится, что ласковый телёнок двух маток сосёт. Навстречу приветливым словам раскрываются сердца людей. Скажешь не подумав или поспешишь с ответом — ошибки не миновать.



*Алтмыш бишенче тәрбия*

## АШЫГЫП ЭШ КЫЛГАН КЕШЕ ҮКЕНЕЧКӘ ТАРЫМЫЙ КАЛМАС

Һәр эшнең ахырын фикер кыйлып вә уйлап эш кыйлган кеше бәла вә кайгыдан имин булыр вә сәламәт калыр. Уйламаенча, ашыгып эш кыйлган кеше һичбер тәүбә вә үкенеч тартмай калмас.

*Наставление шестьдесят пятое*

## ТОТ, КТО ТОРОПИТСЯ, НЕПРЕМЕННО ПОЗНАЕТ ГОРЕЧЬ РАСКАЯНИЯ

Тот, кто думает о последствиях своих поступков, избавит себя от многих бед и огорчений. Тот же, кто всегда торопится и ни о чем не думает, непременно познает горечь раскаяния.



*Алтмыш алтынчы тәрбия*

## БЕР ҖИРГӘ КЕРГӘНЧЕ, ӘҮВӘЛ АННАН НИЧЕК ЧЫГАСЫҢНЫ УЙЛА

Әй угыл, бер йиргә керсәң, әүвәл ничек итеп чыгасыңны уйламак кирәк... Бер ишекне ачсаң, ничек итеп ябармын дип уйламак кирәк. Ягъни бурычка керсәң, ничек итеп түләрмен дип, әүвәл түләвеңне искә төшер. Вә дәхи бер эшкә керешсәң, ничек итеп тәмам кыйлырмын дип, тәмам кыйласыңны искә төшер.

*Наставление шестьдесят шестое*

## ПРЕЖДЕ ЧЕМ ВОЙТИ, ПОДУМАЙ, КАК ВЫЙТИ

О сын мой, прежде чем войти, подумай, как выйти... Открывая дверь, подумай, как её затворить. Влезая в долги, подумай, чем будешь расплачиваться. И вообще, за какое бы дело ты ни взялся, заранее прикинь, сможешь ли довести его до конца.



*Алтмыш җиденче тәрбия*

## БЕР МӘРТӘБӘ ЯЛГАНЛАСАҢ, ЧЫН СҮЗЕҢӘ ДӘ ЫШАНМАСЛАР...

Ялганчылык белән аты чыккан кеше, һәрникадәр тугры сүз әйтсә дә, ышандырмайдыр. Бер мәртәбә ялганчылыгың сизелсә, чын сүзеңә дә ышанмас булырлар...

*Наставление шестьдесят седьмое*

## СОВРЁШЬ ОДИН РАЗ, НЕ ПОВЕРЯТ И ПРАВДЕ ИЗ ТВОИХ УСТ

Человеку, прослывшему лжецом, не поверят, если даже слова его — чистейшая правда. Соврёшь один только раз — а доверия лишишься на всю жизнь...



*Алтмыш сигезенче тәрбия*

## ЯМАН ХОЛЫКЛЫ ЗАТЛАРДАН ЕРАК ЙӨР, КҮРКӘМ ХОЛЫКЛЫ ЗАТЛАРДАН АЕРЫЛМА

Әгәр вак вә түбән җанлы кемсәнәләр вә наданнар олуглар дәрәҗәсенә ирешсәләр, олуглар вә кешелекле адәмнәр һәлак дәрәҗәсенә төшәрләр, ягъни яхшы күңелле адәмнәрнең кадере калмас. Әй угыл, яман холыклы вә тар холыклы кемсәнәләрдән кач вә ерак кит, күркәм холыклы кемсәнәләрдән аерылма вә әхлакы күркәм белән тиңдәш бул.

*Наставление шестьдесят восьмое*

## ОТ ДУРНЫХ ЛЮДЕЙ БЕГИ КАК ОТ ОГНЯ И НЕ РАЗЛУЧАЙСЯ С ЛЮДЬМИ ДОБРЫМИ

Если бы власти и величия добились невежественные, низкие люди, то почтенным, по-настоящему добродетельным людям пришлось бы худо, ибо их перестали бы ценить. О сын мой, от дурных людей беги как от огня и не разлучайся с людьми добрыми, любезными в общении, заслужи их уважение похвальным поведением.



*Алтмыш тугызынчы тәрбия*

## АВЫЗЫҢНАН ЧЫККАН КИРЕ КАЙТМАС

Әй угыл, әйткән сүз аткан ук кебек, һәрбер сүзне уйлап сөйләшергә кирәк, авызыңнан чыккан кире кайтмас. Гөнаһлы була торып та, тәүбәгә ашыкмаган кешенең гөнаһы, кечкенә булса да, зурга әйләнә.

*Наставление шестьдесят девятое*

## СКАЗАННОГО НЕ ВЕРНЁШЬ

О сын мой, слово что стрела, пущенная с тетивы, хорошо подумай, прежде чем сказать. Сказанного ведь не вернёшь.

Если согрешивший не спешит покаяться, то проступок его, пусть и маленький поначалу, со временем становится большим грехом.



*Җитмешенче тәрбия*

## АКЫЛ БЕЛӘН ТОТСАҢ, АЗ НӘРСӘ ДӘ БӘРӘКӘТЛЕ

Тәдбир белән тотсаң вә сарыф кыйлсаң, аз нәрсә дә бәрәкәтле буладыр, вә тәдбирсез тотып исраф кыйлсаң, күп нәрсә дә йитмәйдер...

Әй угыл, сиңа монда тәрбия шулдыр ки: көнендә ун тиен файда итсәң иде, шуның сикез тиенен чыгымнарыңа тотып, калганы сәрмаяңа кушылсын — гомергә фәкыйрь булмассың, мохтаҗлык күрмәссең. Әгәр ун тиен файда итеп тә, унбер-унике тиен чыгым тотсаң, тиз эштән чыкарсың. Заманымызда гайрәтләр бик күп булды. Файда итмәгән көн икмәк белән су ашап торсаң да ярар.

Әй угыл, гакыллы кеше шулдыр ки, кулындагын саклар, бу көнге эшен иртәгә калдырмас.

*Наставление семидесятое*

## ЕСЛИ ТРАТИТЬ С УМОМ, ТО И МАЛОГО БУДЕТ ДОВОЛЬНО

Если тратить с умом, то и малого будет довольно, в то время как расточительному и многого мало.

О сын мой, мой тебе совет: если зарабатываешь ты десять копеек в день, используй на свои нужды восемь из них, а остальное добавь к своему капиталу — и не будешь ты беден. Если же, зарабатывая десять копеек, тратишь ты одиннадцать-двенадцать, разоришься быстро. Немало было таких смелых, желающих пустить пыль в глаза на нашем веку. В день, когда не было прибыли, можно и хлебом с водой пообедать.

О сын мой, умён тот, кто бережлив и не откладывает на завтра то, что можно сделать сегодня.



*Җитмеш беренче тәрбия*

## ХӨРМӘТ ҺӘМ ДАН ОЗЫН БУЙ, ЮАН КОРСАК БЕЛӘН ТҮГЕЛ, Ә ТЫРЫШЛЫК БЕЛӘН ЯУЛАНА

Гыйззәтлелек вә олуглык — зур тырышлык беләндер, чергүче туфрак белән иңмәсдер, ягъни озын буй вә олуг сакал, вә җуан корсак белән түгелдер. Болар барысы да череп туфрак буласы нәрсәдер, олуглыкка илтә торган нәрсә түгелдер. Зур тырышлыктан вә күркәм әхлактан ялангач булып та, буй белән вә җәмал белән, вә кыяфәт белән олуглыкны эстәмәк — гаять ахмаклыкдыр. Вә дәхи олуглык вә игелеклелек дигән нәрсә гыйлем вә әдәп беләндер вә күркәм әхлак беләндер. Юк исә, күл өстендә яхшы атлар юргалату бер дә олуглыкка вә хөрмәткә илтмәйдер. Әй угыл, адәм булаем дисәң, мондаен юк эшләргә ихлас куйма.

*Наставление семьдесят первое*

## УВАЖЕНИЕ И СЛАВА ДОБЫВАЮТСЯ УСЕРДНЫМ ТРУДОМ, А НЕ БОЛЬШИМ РОСТОМ И ТОЛСТЫМ БРЮХОМ

Почёт и авторитет добываются усердным трудом, а не большим ростом, длинной бородой и толстым брюхом. Всё это — блажь, далёкая от подлинного величия. Глупо уважать людей лишь за их почтенную внешность, если нет за ней ни ума, ни доброты. Учёность, воспитанность, прекрасные душевные качества — вот за что следует почитать. Гарцевать на добрых иноходцах у озера — это занятие не для почтенных людей. О сын мой, если хочешь быть человеком, никогда не занимайся подобными пустяками.



*Җитмеш икенче тәрбия*

## ГЫЙЛЕМ ИЯСЕ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ ИСЛЕМАЙ САТУЧЫ ЯНЫНДА ТОРГАН КЕБЕК...

Гакыл ияләре белән вә гыйлем әһле белән аралашу вә сер кыйлмак күңелләрне тергезер. Вә гыйлем вә мәгърифәт әһле белән сер кыйлмак ислемай сатучылар янында тормак белән бәрабәрдер ки, гәрчә сиңа ул ислемай бирмәсә дә, хуш исе борыныңа керәдер. Наданнар вә явызлар белән гәпләшү — тимерчеләр янында тормак белән бәрабәрдер: очкыннары сиңа килеп сачрар, шулай ук наданның наданлыгы әсәр итәдер...

*Наставление семьдесят второе*

## ПОСЛУШАТЬ МУДРЕЦА — СЛОВНО ПОСТОЯТЬ ВОЗЛЕ ЛАВКИ ТОРГОВЦА БЛАГОВОНИЯМИ

Послушать мудреца — удовольствие для души, словно бы постоять возле лавки торговца благовониями: хотя и не перепадёт тебе ничего, зато вволю ароматом надышишься. Послушать невежду или злого человека — всё равно что побывать в кузнице: как искры обжигают тело, причиняя боль, так невежество обжигает душу.



*Җитмеш өченче тәрбия*

## КЕШЕНЕҢ ЭШЕНДӘ ЯКИ СҮЗЕНДӘ ХАТА КҮРСӘҢ, ТӨЗӘТМӘ

Әй угыл, кешенең эшендә яки сүзендә хата күрсәң: «Һай, хата кыйлдың, болай кирәк», — дип хатасын төзәтмә, чөнки синнән гыйлем һәм алыр, сине дошман һәм тотар. Бу эш үз башыма күп килгәне бар, вә ничә мәртәбә кешенең хатасын үгрәтеп үкенгәнем бар.

*Наставление семьдесят третье*

## ЕСЛИ ЗАМЕТИШЬ ОШИБКУ В ЧЬИХ-ЛИБО СЛОВАХ ИЛИ ДЕЛАХ, НЕ ГОВОРИ ОБ ЭТОМ

О сын мой, если заметишь ошибку в чьих-либо словах или делах, не вздумай сказать об этом, ибо, даже признав твоё замечание справедливым, человек не простит тебе твоих слов. В этом я убедился на собственном опыте. Сколько раз я пытался делать людям замечания, столько же раз мне приходилось горько раскаиваться в этом.



*Җитмеш дүртенче тәрбия*

## ФАЙДА КИТЕРЕРГӘ КУЛЫҢНАН КИЛМИ ИКӘН, ЗАРАРЫҢ БУЛСА ДА ТИМӘСЕН

Адәмнең табигате шуйләдер ки, мәнфәгатен күргән кешегә мәхәббәтле булыр, зарар китергән кешегә рәнҗер. Әй угыл, кешегә файда китерергә кулыңнан килми икән, зарарың булса да тимәсен. Ачык йөзле, татлы сүзле бул — дустың күп булыр.

*Наставление семьдесят четвёртое*

## НЕ МОЖЕШЬ ПОМОЧЬ ЛЮДЯМ, ТАК ПО КРАЙНЕЙ МЕРЕ НЕ ПРИЧИНЯЙ ИМ ЗЛО

Природа человека такова: мы любим тех, кто сделал нам добро, и терпеть не можем людей, причинивших нам зло. О сын мой, если уж не можешь помочь людям, так по крайней мере не причиняй им зла. Будь приветлив, мягок в обращении, и у тебя будет много друзей.



*Җитмеш бишенче тәрбия*

## МАЛНЫ САКЛАУ АНЫ ТАБУ БЕЛӘН ҖЫЮДАН АВЫРРАК

Әй угыл, мал кәсеп кыйлуның тарикы (юлы) бик күпдер. Нинди генә юл булмасын, малны хәләлдән табу фарыздыр. Хәләлдән килгән мал тотрыклы буладыр. Хәрам мал исә адәмгә йокмайдыр; тиз кулыңнан китәр, җаваплылыгы һәм авырлыклары гына сиңа калыр. Әмма хәләлдән кәсеп иткән малыңны саклап тот, хәрам йиргә сарыф итмә. Малны сакламак малны җыймактан мөшкелрәкдер. Саклап тота белмәгәнлек сәбәпле, никадәр бай кемсәнәләр дәүләт-мөлкәттән мәхрүм калдылар.

*Наставление семьдесят пятое*

## СБЕРЕЧЬ БОГАТСТВО ТРУДНЕЕ, ЧЕМ НАКОПИТЬ ЕГО

О сын мой! Достичь благополучия можно многими путями. Но каковы бы ни были они, лучше всего избрать путь честный, ибо богатство, нажитое честным трудом, самое надёжное. Нечестно нажитое добро быстро утечёт сквозь пальцы, а вся ответственность и грехи падут на тебя. Честно заработанное не используй на дела нечестивые. Сберечь богатство труднее, чем накопить его. Из-за неумения беречь его многие богачи остались ни с чем.



*Җитмеш алтынчы тәрбия*

## ЧЫГЫМНАРЫН САНАП ТОТКАН КЕШЕ МОХТАҖ БУЛМЫЙ

Әй угыл, малның килүенә карап байлыгыңны тот, чыгымнарың керемеңә караганда кимрәк булсын, шулчакта дөньяда һич мохтаҗ булмассың. Һәр көн азмы-күпме чыгымнарыңнан артканы сәрмаяңа кушылсын, байлыгың һаман арта барыр. Инде малың күп булган очракта, фәкыйрь вакытыңны онытма, фәкыйрь чагыңда: «Бу нәрсә бу көнгә йитсен», — дип сарыф кыйладыр идең, бай булгач та, әнә шундый ук хисап белән тот. Чыгымнарын үлчәп тоткан кеше мохтаҗ булмайдыр.

*Наставление семьдесят шестое*

## КТО ВЕДЁТ УЧЁТ СВОИХ ЗАТРАТ, ТОТ НУЖДАТЬСЯ НЕ БУДЕТ

О сын мой, тратя деньги, помни об их источнике, пусть расход твой будет меньше прихода, тогда ты не познаешь нужды. Пусть изо дня в день кое-что из денег, оставшихся после расходов на жизнь, добавляется в копилку, и благополучие твоё упрочится. Однако, став богатым, не забывай о былой нужде, когда ты говорил: «Этого на один день будет довольно». Будь так же бережлив. Кто ведёт учёт добра, нуждаться не будет.



*Җитмеш җиденче тәрбия*

## ӘМАНӘТНЕ ҮЗ МАЛЫҢ КЕБЕК ИТЕП САКЛА

Вә әгәр бер дустың яки карендәшең малын яки хезмәтен сиңа тапшырса вә әманәт итсә, үз малың кебек итеп сакла, вә үз хезмәтең кебек итеп башкар. Ул сәбәпле Аллаһ Тәгалә синең малыңа бәрәкәт бирер, вә халык арасында әманәткә тугры булып мәшһүр булырсән. Әмма, әй угыл, малыңнан бер нәрсәне бер кешегә әманәт куяем дисәң, исраф итүче адәмгә әманәт куйма. Дәхи комарбазга, ягъни отыш уен уйнаучы кешегә вә хәмер эчкүчегә әманәт куйма.

*Наставление семьдесят седьмое*

## ПЕРЕДАННОЕ ТЕБЕ НА ХРАНЕНИЕ ДОБРО БЕРЕГИ, КАК СВОЁ СОБСТВЕННОЕ

Если кто-нибудь из друзей или родственников передаст тебе на хранение добро, береги его, как своё собственное, словно ты нажил его своим трудом. Честно выполни просьбу, и Аллах благословит тебя. И люди увидят, что ты достоин доверия. Но если, сын мой, тебе самому случится отдать на хранение вещи или деньги, не поручай это транжире, азартному игроку, пьянице.



*Җитмеш сигезенче тәрбия*

## КЕМГӘ БУРЫЧЛЫ БУЛСАҢ, ШУҢА КОЛЛЫККА ТӨШӘРСЕҢ

Вә дәхи, әй угыл, бурыч итәргә һәвәс итмә. Вә файда белән алма, вә заклад биреп акча алма. Чөнки бу эшләр адәмне хурлыкка төшерер. Чөнки кемгә бурычлы булсаң, аңар кол булырсән. Вә дәхи кешегә бурычка акча бирмә, хосусан дустыңа бирмә. Чөнки дустың вакытында үзе белеп бирмәсә, тәкрар сорамак туры килер, сорасаң — рәнҗер, араңызда дустлык бетәр. Дустыңны дошман итмәк җаһиллар эшедер.

*Наставление семьдесят восьмое*

## ТЫ СТАНЕШЬ РАБОМ ТОГО, КОМУ ЗАДОЛЖАЕШЬ

Не стремись делать долги, сын мой. Не связывайся с ростовщиком, не закладывай вещи. Это путь к позору. Ибо ты станешь рабом того, кому задолжаешь. А также не давай деньги в долг, тем более близкому другу. Если он не сможет вернуть их в срок, придется напоминать много раз, а это повлечёт за собой недовольство, и дружба ваша кончится. Только глупец решится заменить своего лучшего друга недругом.



*Җитмеш тугызынчы тәрбия*

## ӘГӘР БЕР КЕШЕ СИҢА ӘМАНӘТ БИРЕРГӘ ТЕЛӘСӘ, ҮЗЕҢӘ БӘЛА АЛМА

Әй угыл, әгәр бер кеше сиңа әманәт куерга теләсә, кабул итмә, үзеңә бәла йөкләмә. Чөнки әманәт саклау — бер бәладер, өч хәвефле ягы бар. Әманәт нәрсәне үз малларыңнан артыграк итеп сакламак белән зәхмәт чигәрсән һәм иясенә тапшырырсән. Яки кеше әйберен үзеңә алырга теләп, синнән әманәт алганым юк, дип инкяр кылырсән. Яки әманәт югалыр, ихтималдыр, аннан соң оятка калырсән. Каза күрдем, югалды дисәң дә ышанмас. Бәс, әманәт сакламак — җиңел эш түгелдер. Әмма әгәр дә әманәтне кабул итсәң, яхшы сакла һәм хыянәт итмә. Әгәр берәү үзеңә сатарга бер нәрсә әманәт куйса, сатканнан соң, тоткарланусыз, акчасын иясенә тапшыр. Әмма моны әда кыйла алмассән, әманәт итеп алма; яки саткач, акчасын бирермен фәләнчә вакыттан соң дип, бер мөддәт тәгаен кыйлып, вәгъдәгә ал.

*Наставление семьдесят девятое*

## ЕСЛИ КТО-ТО ЗАХОЧЕТ ОСТАВИТЬ ВЕЩЬ У ТЕБЯ НА ХРАНЕНИЕ, НЕ БЕРИ НА СЕБЯ ЛИШНЮЮ ОБУЗУ

О сын мой! Если кто-то захочет оставить вещь у тебя на хранение, не принимай её, не бери на себя лишнюю обузу. Ибо дело это таит в себе три опасности. Чужую вещь ты должен беречь пуще своего богатства и возвратить владельцу. Или ты можешь польститься на чужую вещь и, желая оставить её себе, отрицать, что брал её. Может случиться и так, что вещь потеряется, а ты окажешься в неловком положении и осрамишься. И не поверят твоим словам, что случилась беда и чужое имущество потерялось. Да, сын мой, хранить чужую вещь — дело нелёгкое. Но уж коли ты согласился на это, береги её и не злоупотребляй доверием. Если же кто-то попросит тебя что-то продать, тотчас же верни хозяину деньги, вырученные за проданную вещь. Если уж ты не можешь выполнить просьбу, лучше не берись за дело.



*Сиксәненче тәрбия*

## ХӘЛӘЛ СӘҮДӘ БЕЛӘН АЛЫНГАН БЕР ТИЕНЕҢ УН ТИЕН ХӘРАМЫҢНАН ӨСТЕН

Һөнәрле кол үлмәс. Әй угыл, һөнәрең кайсы булса да, үзең яхшы булсаң, акча китерәдер. Әмма һөнәрләрнең яхшысы, әгәр дә азрак сәрмаяң (акчаң) булса, сәүдә кыйлмак яхшы кәсепдер. Ләкин хәләл сәүдә кыйлмак бик читен эшдер. Әмма ижтиһад кыйл, әй угыл, хәләлдән сату ит. Хәләл сәүдә белән хасил иткән бер тиенең ун тиен хәрамыңны бәреп җыгар. Сәүдә малы алсаң, малның яхшысын ал, чөнки яхшы нәрсәдән файда өмиде бар, начар нәрсәң сатылмай калса, зарар булыр.

*Наставление восьмидесятое*

## ОДНА МОНЕТА, ЗАРАБОТАННАЯ ЧЕСТНОЙ ТОРГОВЛЕЙ, СТОИТ ДЕСЯТИ, ПОЛУЧЕННЫХ ОБМАНОМ

Обученный ремеслу не пропадёт и в рабстве. Любая работа даст тебе надёжный кусок хлеба, сын мой, лишь бы сам ты был хорошим человеком. Когда есть кое-какие сбережения, особенно выгодно заниматься торговлей.

Однако торговать честно — дело нелёгкое. И всё же рискни, сын мой, и будь честен. Одна монета, заработанная честью, стоит десяти, полученных обманом. Закупая товар, смотри, чтобы он был хорошего качества, плохой товар залежится в лавке и принесёт одни убытки.



*Сиксән беренче тәрбия*

## САТУ-АЛУ ЭШЕНДӘ ЯЛГАН СӨЙЛӘМӘ, АНТ ИТМӘ

Һәм тагын, әй угыл, адәм һәм хайван ризыгы булган нәрсә белән алу-сату итмә. Ягъни икмәк-ашлыкны арзан вакытта алып, кыйммәтләнгәч яки юклык һәм ачлык елда сатармын дип ашлыкны җыеп саклау — хәрам. Моны спекуляция диләр, һәм тагын, әй угыл, сату-алу эшендә ялган сөйләмә, ант итмә. Әмма сату-алуны җиңел кыйл. Әмма башка кешегә шәрик булып сәүдә кыйлудан саклан, чөнки дөньяда гадел кеше аздыр, низагтан башың чыкмас. Сынамаган вә тәҗрибә кыйлмаган мал белән сату итмә; үзеңнең үгрәнгән сәүдәңне ташлама.

*Наставление восемьдесят первое*

## НИКОГДА НЕ ОБМАНЫВАЙ И НЕ ДАВАЙ ПУСТЫХ ОБЕЩАНИЙ ПРИ КУПЛЕ-ПРОДАЖЕ

Сын мой, остерегайся торговать хлебом насущным. Ибо самый нечестный путь, когда человек, купив урожай по дешёвке, хранит его, чтобы во время нужды или голода продать дороже. Это спекуляция. И ещё, сын мой, никогда не обманывай и не давай пустых обещаний при купле-продаже. Не стремись торговать с компаньоном: мало в мире справедливых, честных людей, потом склок не оберёшься. Торгуй только проверенным товаром, не бросай привычное ремесло.



*Сиксән икенче тәрбия*

## АХМАК ҺӘМ НАДАН АДӘМ ДУСЛЫККА ДА, ДОШМАНЛЫККА ДА ЯРАМАС

Әй угыл, «гадүе гакыйл хәер мин садыйки җаһил»[1]. Ахмак вә надан адәм дустлыкка вә дошманлыкка һәм ярамас. Вә һөнәрсез кеше дустлыкка ярамас. Саклан шул кешедән ки, үзе бернәрсә белмәс, үзен галим вә белекле санар. Бер эшне бер мәртәбә эшләп тугры килмәсә, икенче мәртәбә ул эшкә тотынма, вә кулыңнан килмәгән эшкә тотынма.

*Наставление восемьдесят второе*

## ГЛУПЫЙ И НЕВЕЖЕСТВЕННЫЙ ЧЕЛОВЕК НЕ ГОДИТСЯ НИ В ДРУЗЬЯ, НИ ВО ВРАГИ

О сын мой, умный враг лучше глупого друга. Глупый и невежественный человек не годится ни в друзья, ни во враги. Неумелый также не годится быть другом. Постарайся избегать и тех, кто ничего не знает, а корчит из себя умника.

Если, попробовав что-то сделать, не добился ты нужного результата, в другой раз не трать напрасно времени, не берись за дело, которого тебе не осилить.

---

[1] «Акыллы дошман надан дустан яхшырак» мәгънәсендә.



*Сиксән өченче тәрбия*

## ӘГӘР ДОШМАН СЕРЕМНЕ БЕЛМӘСЕН ДИСӘҢ, АНЫ ДУСТЫҢА ДА ӘЙТМӘ

Әй угыл, гәрчә тугры сөйләмәк ачыдыр, әмма тугры сөйлә. Әгәр дошман серемне белмәсен дисәң, дустыңа да сереңне әйтмә, таки дошманыңа барып әйтмәсен.

Олугларны олуг ит, кечеләргә шәфкатьле бул.

Надан вә һөнәрсез кешеләрне тереккә сайма, мәет дип бел.

Бер эшне ике мәртәбә эшләмә.

*Наставление восемьдесят третье*

## ЕСЛИ ХОЧЕШЬ СКРЫТЬ ТАЙНУ ОТ ВРАГА — НЕ ДОВЕРЯЙ ЕЁ И ДРУГУ

О сын мой, хотя и горька правда, никогда не криви душой.

Если хочешь скрыть тайну от врага, не доверяй её и другу.

Будь почтителен со старшими и не обижай младших.

Невежды и бездельники пусть будут всё равно что мертвы для тебя, не считай их за живых людей. Не делай дважды одно и то же дело.



*Сиксән дүртенче тәрбия*

## ҮЗЕҢНӘН ТҮБӘН ДӘРӘҖӘДӘГЕЛӘРГӘ МОХТАҖ БУЛУДАН САКЛАН

Һиммәтсез (эшлексез) кешенең икмәген ашаудан ач тормак артыкдыр.

Сынамаган вә тәҗрибә кыйлмаган кешегә таянма, мең төрле түбәнчелекләр кыйлса да.

Үзеңнән түбән дәрәҗәдәгеләргә мохтаҗ булудан бик саклан ки, моннан кыен эш юкдыр. Бурычтан бик саклан, әй угыл, кешегә бурычлы булдың — аңа кол булдың.

*Наставление восемьдесят четвёртое*

## НЕ СТАВЬ СЕБЯ В ЗАВИСИМОСТЬ ОТ ЛЮДЕЙ НИЖЕ ТЕБЯ ПО ПОЛОЖЕНИЮ

Лучше остаться голодным, чем притронуться к хлебу бездельника.

Бойся доверять человеку, которого знаешь мало, пусть он и оказывает тебе тысячу знаков внимания.

Не ставь себя в зависимость от людей ниже тебя по положению, этим ты избавишь себя от чувства неловкости. Избегай быть в должниках у кого-то, о сын мой, сразу станешь ты его рабом.



*Сиксән бишенче тәрбия*

## УРЛАНГАН НӘРСӘНЕ БЕЛӘ ТОРЫП АЛУ ҮЗЕҢ УРЛАГАНГА ТИҢ

Әй угыл, угырланган нәрсәне алмактан бик саклана күр. Кирәк үзең угырла, кирәк белә торып угырлаган нәрсәне ал — икесе бәрабәрдер. Аңсыздан угырланган нәрсә кулыңа керсә, үзеңдә калдырма, иясенә тапшыра күр.

*Наставление восемьдесят пятое*

## УКРАСТЬ САМОМУ ИЛИ КУПИТЬ ВЕЩЬ, ЗАРАНЕЕ ЗНАЯ, ЧТО ОНА КРАДЕНАЯ,— ОДНО И ТО ЖЕ

О сын мой, остерегайся покупать краденое. Украсть самому или купить вещь, заранее зная, что она краденая, — одно и то же. Если же краденое добро попадёт к тебе случайно, поспеши вернуть его хозяину.



*Сиксән алтынчы тәрбия*

## ДУС БУЛЫП КЫЛАНЫП, ЭЧЕНДӘ ДОШМАНЛЫК ҺӘМ КӨНЧЕЛЕК ЯШЕРЕП ЙӨРГӘН КЕШЕДӘН БИК САКЛАН

Әмма, әй угыл, тышыннан дустлык күрсәтеп, эчендә дошманлык вә хөсед яшереп йөргән кешедән бик саклан. Бу заманның дустларына да ышанма. Берәү сине алдыңда мактаса, әлбәттә, белгел ки, һичшиксез, сине артыңда яманлый торгандыр. Тәҗрибә кыйлмай торып алданма.

*Наставление восемьдесят шестое*

## БЕРЕГИСЬ ЛЮДЕЙ, КОТОРЫЕ ПРИКИДЫВАЮТСЯ ДРУЗЬЯМИ, А НА САМОМ ДЕЛЕ ПОЛНЫ ЗАВИСТИ И ЗЛОБЫ

Сын мой, берегись людей, которые прикидываются друзьями, а на самом деле полны зависти. Не очень-то доверяй людям. Многие будут хвалить тебя в глаза, но можешь не сомневаться, что за глаза они же тебя и осудят. Не дай провести себя, сперва испытай друга.



*Сиксән җиденче тәрбия*

## ЯХШЫ СҮЗ БЕЛӘН ЯВЫЗНЫ ХАК ЮЛГА САЛЫРМЫН, ДИМӘ

Әй угыл, яхшы сүз белән усалны юлга салырмын, димә.

Ахмак үз-үзенә кыйлган кадәр зарарны гакыллы адәм дошманына да кыйлмас.

Әгәр, әй угыл, сине алдыңда мактасалар вә тәшәккер кыйлсалар: «Һай рәхмәт! Мине мактайсыз икән ләбаса», — димә, эчеңнән тын.

Әгәр дустларым күп булсын дисәң, кеше эшенә катышма вә һичкемгә бәйләнмә — һәммә халык сиңа дуст булыр.

*Наставление восемьдесят седьмое*

## НЕ СТАРАЙСЯ ИСПРАВИТЬ ЗЛОГО ЧЕЛОВЕКА ДОБРЫМ СЛОВОМ

